ПӘНҖЕШӘМБЕ
4 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 78 (5878)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ВКП (б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ ПЛЕНУМЫ ТУРЫНДА

Шушы көннәрдә ВКП(б) Үзәк Комитетының чираттагы пленумы булды.

Пленум хөкүмәтнең тышкы политикасы турында һәм Финляндия белән сугыш йомгаклары турында белдерүләр тыңлады һәм аларны яхшы дип тапты.

Пленум махсус карарлар кабул итте: а) Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләүләр һәм сатып алулар политикасындагы үзгәрешләр турында һәм б) Экономсоветның эшен үзгәртеп кору турында.

Пленум шушы елның июнь аенда партиянең Бөтенсоюз конференциясен чакырырга карар бирде.

АЛГАН ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

Данлыклы Беренче Май бәйрәмен һәм республикабызның XX еллыгы якынлаша. Бөек датылар хөрмәтенә булган социалистик ярыш көннән-көн киңәя һәм бу ярыш чын-чыннан большевикларча оештырылган җирдә үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Һәрбер намуслы хезмәт иясе бердәм теләк белән сугарылган. Һәр ике бәйрәмне дә халык хуҗалыгының барлык тармакларында да яңа уңышлар белән каршыларга, партия һәм хөкүмәтебез заданиеләрен намус белән тулы үтәргә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең яңа үрнәкләрен күрсәтергә, моның өчен бай техникадан тулы файдаланырга—бердәм теләк әнә шундый.

Данлыклы Кызыл Армиябезнең һәм Хәрби Диңгез Флотыбызның гаять зур һәм тарихи казанышы, илебезнең Сталинчыл тынычлык политикасының яңа тантанасы халкыбызны тагын да яхшырак эшләргә, социалистик Ватаныбызның экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгытуга рухландыра. Совет хөкүмәте башлыгы һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш Молотовның СССР Верховный Советы Сессиясендә ясаган тирән эчтәлекле докладына җавап итеп, совет халкы, шул исәптән республикабыз хезмәт ияләре дә, үзенең Ленин—Сталин партиясе эшенә, бөек Сталин эшенә чиксез бирелгәнлеген, Ватан өчен, Сталин өчен кирәк моментта актык тамчы канын да бирергә хәзер торганлыгын тагын да бер кат ачык итеп белдерде. Совет халкының үз Ватанына карата булган кайнар мәхәббәте бөтен дөньяда гаять көчле булып яңгырый.

Орденлы Татарстан республикасының алдынгы предприятие коллективлары үз йөкләмәләрен тиешенчә эш белән ныгыталар. Дәүләт планын тулы һәм арттырып үтәүче предприятиеләр, цехлар, группалар һәм бригадалар сафы көн саен үсә. Мәсәлән, Казандагы киез итек-фетр фабрикасы, Ильич исемендәге механика заводы, мехкомбинат, тегү фабрикасы, „Спартак“ комбинаты кебек байтак кына предприятиеләр 1940 нчы елның 1 нче квартал планын арттырып үтәделәр. Серго Орджоникидзе исемендәге заводта иптәш Павлов участкасы, М. Горький исемендәге заводта иптәш Сессин группасы план үтәлешен 150—180 проценттан кимитмиләр. Бу җиңүне, барыннан да элек, социалистик хезмәт массаларга—стахановчыларга һәм ударниклар армиясе тәэмин итте. Монда берьюлы берничә станокка хезмәт күрсәтү, беренче профессияне үзләштерү хәрәкәте, рационализаторлар һәм уйлап табучылар хәрәкәте, киртеләрнең кыйммәтле тәкъдимнәрен тормышка ашыру чаралары гаять зур урын тота һәм стахановчылык хәрәкәтенең бу яңалыклары алдынгы предприятиеләребездә көннән-көн үзенең мактаулы урынын ала. Бу чаралар хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен безнең предприятиеләребездә гаять зур эчке мөмкинлекләр барлыгын ачыклый.

Бурыч, алдынгыларга тигезләнүдән, барлык предприятиеләрнең дә тәгәл эшләүләрен тәэмин итүдән, республикабыз промышленностеның һәм шулай ук транспортның артта калучыларын бетерүдән тора. Татарстан большевикларының XXI нче өлкә конференциясе күрсәтмәләрен тайпылышсыз рәвештә тормышка ашырудан, массалар алдында торган әнә шул бурычларны уңышлы хәл итүгә оештырудан гыйбарәт.

Ләкин бу мактаулы һәм җаваплы бурыч кайбер предприятиеләр тарафыннан үтәлми әле. Моны без җирле промышленность наркоматы системасындагы предприятиеләр мисалында гына да күрә алабыз. Нарком иптәш Филимонов эштә булган кайбер уңышлар белән мавыгып, артта калучы участокларны күрми. Булган мәгълүматлардан чыгып тегә яки бу предприятиенең эшенә большевистик анализ ясамый. Нәтиҗәдә пыяла заводы һәм Татполиграф беренче квартал планын үтәүдә әзерләр (80—82 процент). Гомумән наркомат системасындагы предприятиеләр быел узган елгыга караганда начаррак эшлиләр. Бу елның беренче квартал планы бары 91,8 процентка гына үтәлде.

1939 нчы елның планын арттырып үтәгән, ә быел артка чигенгән җиркомбинат (директоры иптәш Логинов) турында да шулай ук әйтергә мөмкин. Комбинат җитәкчелеге масса активлыгын беренче казанышларны ныгыту өчен кирәкле эшкә вакытында тупламады. Социалистик ярышның формаль рәвештә генә оештырылуы, алынган йөкләмәләрнең бик тиз онытылуы аркасында, комбинат беренче квартал планын үтәмәде. План үтәлеше 82 процент кына тәшкил итә.

План үтәлешен 60—70 процентка гына җиткерүче җитен комбинатының хурлыклы рәвештә койрыкка сөйрәлүенең сәбәпләре нәрсә белән аңлатырга соң? Сәбәп, эш процессларын белән җитәкчеләрнең таркаулыгында, җитәкчеләрнең тиешле таләп итмәүдә. Социалистик ярышта коллектив да конкрет йөкләмәләр алды. Ләкин ул йөкләмәләрне үтәү өчен көрәшмәде. Андый коры сөйләнчекләр кемгә кирәге бар соң?

Казан тимер юлы җитәкчеләре дә (начальнигы Пингин һәм политбүлек начальнигы Мануров) коры шапырынулардан ерак үзе алганнары юк. Казан тимер юлы әле дә булса начар эшләвен дәвам иттерә, йөк ташу һәм пассажир ташу планын үтәми. Монда аерым рекордлар ярдәмендә эштә булган бай-башташлыкларны читләтеп үтәләр.

„Промышленность һәм транспорт алдында торган бурычларны уңышлы хәл итү һәм тормышка ашыру өчен партия оешмалары эшенең тамырыннан яхшыртырга, стахановчылык хәрәкәтен һәм аның иң югары формасы булган күп станокчылар хәрәкәтен киң җәелдерергә һәм популярлаштырырга, администрациянең эшенә көндәлек контрольлек булдырырга һәм аның эшендәге кимчелекләрне тизрәк бетерергә, кимчелекләрне кыюрак тәнкыйть итәргә, хезмәт дисциплинасын ныгытырга һәм үзләрен эштә күрсәткән, Ленин—Сталин партиясе эшенә, коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләрне җитәкче эшләргә кыюрак күтәрергә“. ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе безгә әнә шундый задача куйды. Безнең социалистик ярышта алган йөкләмәләрне практик эш белән ныгыту өчен барлык көчне, барлык игътибарны туплыйк, барлык предприятиеләребездә дә тоташ стахановчыла эшләүгә ирешергә кирәк. Моны безнең партиябез, хөкүмәтебез һәм безнең халкыбызның интереслары таләп итә.

Данлыклы 1 нче Май бәйрәменә һәм республикабызның XX еллыгына производствода яңа уңышлар белән каршылау, дәүләт планының тулы үтәлешен тәэмин итү—һәрбер хезмәт иясенең иң беренче бурычы.

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясе

СОЮЗ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

2 апрель, 1940 ел

2 нче апрельдә, көндез 11 сәгаттә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының 3 нче утырышы булды.

Утырышта Союз Советы Председателенең урынбасары депутат **Усман Юсупов** председательлек итә.

Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Фикер алышуларда депутат **М. Корбанов** (Таҗикстан ССР ның Куляб округы), СССР ның Химия Промышленносте Халык Комиссары иптәш **М. Ф Денисов**, депутатлардан **М. К. Симонженкова** (Москва өлкәсенең Раменское округы), **К. В. Киселев** (БССР ның Вилейка өлкәсе, Глубокое округы) һәм **А. Худайбергенов** (Төркмәнстан ССР ның Ташавыз округы), СССР ның Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш **И. А. Бенедиктов**, депутат **А. Кенжегараев** (Казагстан ССР ның Актүбә округы), хезмәт ияләре депутатларының Москва шәһәр советы башкарма комитеты председателе иптәш **В. П. Пронин**, депутатлардан **Ю. Д. Крих** (УССР ның Тарнополь өлкәсе, Тарнополь округы), **Т. Кулатов** (Кыргызстан ССР ның Җәлал-Абад округы), **А. Я. Вышинский** (Саратов өлкәсенең Вольск округы) һәм **Ф. С. Пистрак** (БССР ның Белосток өлкәсе, Гродно округы) катнаштылар.

Шуның белән Союз Советының Алтынчы Сессиясенең өченче утырышы ябылды.

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

2 апрель, 1940 ел

2 нче апрельдә, кич 6 сәгаттә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Милләтләр Советының өченче утырышы булды.

Утырышта Милләтләр Советы Председателенең урынбасары депутат **М. В. Кулагин** председательлек итә.

Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Фикер алышуларда депутатлардан **Р. К Ибраһимов** (Башкыртстан АССР ның Мәләвез округы) һәм **Г. А. Каркарян** (Нагорно-Карабах автономияле өлкәсенең Степанакерт округы), СССР ның Текстиль Промышленносте Халык Комиссары иптәш **А. Н. Косыгин**, депутатлардан **А. Казакпаев** (Казагстан ССР ның Акмолинск округы), **С. О. Притыцкий** (БССР ның Гродно округы), **М. И. Шевелев** (Төньяк Осетия АССР ның Үзәк шәһәр округы) һәм **В. К. Трутнев** (Татарстан АССР ның Казан авыл округы), СССР ның Җиңел Промышленность Халык Комиссары иптәш **С. Г. Лукин**, депутатлардан **Т. Мирзаев** (Үзбәкстан ССР ның Әндиҗан авыл округы) һәм **И. Ю. Кравчук** (УССР ның Дрогобыч округы) катнаштылар.

Шуның белән Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясенең өченче утырышы ябылды.

СОЮЗ СОВЕТЫНЫҢ 2 нче АПРЕЛЬДӘГЕ УТЫРЫШЫ

2 нче апрельдә, көндез 11 сәгаттә, Кремльдә Союз Советының өченче утырышы булды.

Председательлек итүче—Союз Советы Председателенең урынбасары депутат Усман Юсупов Союз Советы утырышын ачык дип иглан итә. Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Сүз депутат **М. Корбановка** бирелә. Ул Таҗикстан ССР бюджетының елдан-ел үсүен мисаль итеп, Ленин—Сталин милли политикасының тантанасын күрсәтә.

— Таҗикстан хезмәт ияләре Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә, Совет хөкүмәтенең игтибарын һәм ярдәмен көн саен сизеп, зур иҗад инициативасы күрсәтәләр. Иптәш Сталин исемендәге Ферганә каналын искиткеч кыска срокта төзү моның ачык үрнәге. Төзелештә 160 мең хезмәт иясе катнашты.

СССР ның Химия Промышленносте Халык Комиссары иптәш **М. Ф. Денисов** химия промышленностеның 1939 нчы елгы эше турында сөйли. Куәтле яңа заводлар һәм цехлар стройга керделәр. Предприятиеләр моннан элек чит илләрдән китерелгән күп кенә продуктларны хәзер үзләре эшли башладылар. Сессия карамагына кертелгән бюджет химия промышленностен үстерүгә шактый зур сума бирүне күздә тота.

Трибунада—депутат **М. К. Симонженкова.** Ул заемга язылу срокларын бер айга якынайту турында Союз Советының Бюджет Комиссиясенең такдимен яклый һәм халыктан доход налогы, торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем һәм мәҗбүри окладной страхование турындагы яңа законнарның Сессия карамагына кертелгән проектларын расларга такдим итә.

Депутат **К. В. Киселев** Союзный республикаларның барсының да, аерым алганда Белоруссия ССР ның бюджетлары буенча зур сумалар билгеләнүне әйтеп үтә. Аннары ул Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендә хуҗалыкны социалистик нигезләрдә үзгәртеп кору буенча гаять зур эш эшләнүне күрсәтә.

Депутат **А. Худайбергеновның** речe Төркмәнстан ССР бюджетына багышланды. Аның бюджеты Сталинчыл беренче бишьеллыкның беренче елына чагыштырганда быел 16 тапкыр үскән. Мондый бюджет Төркмәнстан хуҗалыгының һәм культурасының тагын да үсүен тәэмин итә.

СССР Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш **И. А. Бенедиктов** авыл хуҗалыгы кирәкләренә 1940 нчы елгы бюджетта шактый зур сумалар билгеләнүне күрсәтеп үтә. Колхозлар һәм МТС лар гаять зур финанс ярдәме алалар, яңа машиналар, яңа техника белән коралланалар. Күп кенә республикалар, крайлар һәм өлкәләр инде язгы чәчүгә керештеләр. Советлар Союзында инде 1 миллион гектар чәчелде. Үткән елга караганда быел туфракта дым күбрәк. Уҗымнарның хәле үткән елгыдан яхшырак. Югары уңыш алу өчен уңайлы шартлар бар.

Депутат **А. Кенжегараев** оборона кирәкләренә 57 миллиард сум билгеләнү бөтен совет халкы тарафыннан бердәмлек белән алкышлап каршы алыначакны әйтә. Ул Казагстан ССР ның үсүе турында сөйли.

Хезмәт ияләре депутатларының Москва шәһәр советының башкарма комитеты председателе иптәш **В. П. Пронин** үзенең речен башкаланың бюджетына багышлый.

Трибунада — депутат **Ю. Д. Крих.** Украинаның көнбатыш өлкәләре хезмәт ияләренең вәкиле буларак, ул үзенең речененң беренче тәэсирле сүзләрен халыкларның бөек юлбашчысы иптәш Сталинга юнәлдерә. Депутат Крих украин телендә сөйли. Социалистик парламент Советлар Союзының бөек семьясенә кергән азат халыкның фикерләрен һәм хисләрен чагылдыручы яңа депутатның речен игтибар белән тыңлый. Депутат Крих хәзер Украинаның көнбатыш өлкәләрендә башланган бәхетле яңа тормыш турында, СССР Верховный Советына сайлауларда коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының җиңүе турында, яңа тудырылган культура учреждениеләренең—мәктәпләрнең, театрларның, больницаларның эше турында сөйли. Ул СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты проектын һәм Бюджет Комиссиясе тарафыннан кертелгән үзгәрешләрне тулысынча яхшы дип таба.

Депутат **Турабай Кулатов** үзенең речендә Кыргызстан ССР ның халык хуҗалыгының һәм культурасының барлык өлкәләрендә гаять зур уңышларга ирешүе турында тулы итеп сөйли.

Аннары сүз СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары депутат **А. Я. Вышинскийга** бирелә.

— Безнең бюджетыбыз, ул—социалистик дәүләт бюджеты. Безнең бюджетыбыз—дөньядагы бер генә капиталистик илдә дә була алмый торган бюджет. Иң бай һәм иң алдынгы капитализм илләре һәр вакыт дефициттан газап чигәләр. Бу, бөтен капиталистик системаның авыр кризис эчендә булуы аркасында килеп чыга.

„Культуралы“ капиталстик илләр белән Советлар Союзы арасында никадәр зур аерма! СССР да 1940 нчы елгы бюджет буенча культура чараларына бирелә торган сумалар 42 миллиард 900 миллион сумга җитәләр һәм үткән елгыдан 4 миллиард 500 миллион сумга артып китәләр.

Совет фәненең уңышлары турында сөйләгәндә иптәш Вышинский СССР Фәннәр Академиясенең соңгы елларда гаять зур фәнни учреждение булып үскәнлеген, илебезнең югары фән үзәгенә әйләнгәнлеген күрсәтә.

— 1939 нчы елның 21 нче декабре Фәннәр Академиясе тарихына онтылмаслык көн булып керде. Бу көнне безнең бөек остазыбыз һәм юлбашчыбыз Иосиф Виссарионович Сталин почетный академик итеп сайланды.

Депутатлар бу сүзләрне озакка сузылган кул чабулар белән каршылыйлар. Иптәш Вышинскийның, Фәннәр Академиясенең эшенә, аның теләкләренә һәм интересларына Совет хөкүмәте башлыгы Вячеслав Михайлович Молотов һәр вакыт игтибар бирә һәм ярдәм күрсәтә дигән сүзләрен ишетү белән кул чабулар тагын кабатланалар.

Язучы **Ф. С. Пестракның**, — БССР ның Гродно сайлау округы депутатының реченнән соң Союз Советының өченче утырышы ябыла.

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫНЫҢ 2 нче АПРЕЛЬДӘГЕ УТЫРЫШЫ

2 нче апрельдә, кич 6 сәгаттә, Кремльдә Милләтләр Советының өченче утырышы булды.

Утырышны Милләтләр Советы Председателенең урынбасары депутат **М. В. Кулагин** ача. Көн тәртибендә—СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турындагы һәм СССР ның 1938 нче елгы бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышулар.

Сүз депутат **Р. К. Ибраһимовка** бирелә. Ул, аның фикеренчә, хәл ителергә тиеш булган күп кенә мәсьәләләрне күтәрә. Мәсәлән, район промышленностеннан ясала торган барлык чигерүләр шул ук районның җирле промышленностен үстерүгә биреләләр. Иптәш Ибраһимов тиешле оешмаларга бу чигерүләрне бер районнан икенче районга—җирле промышленностьны үстерү өчен шундый ук шартлар булган районнарга күчерү хокукын бирергә такдим итә. Аннары депутат Ибраһимов урыннардагы оешмаларны җирле чимал эшләүче предприятиеләрнең эшенә контроль ясауга тартырга, яңа промышленность үзәкләрендә торак төзелеше өчен сумалар гына түгел, бәлки төзү материалларыннан ныклы фондлар да билгеләргә такдим итә.

Депутат **Г. А. Каркарян** Азербайҗан ССР ның 1938 нче елгы бюджетының доход өлеше канәгатләнерлек үтәлмәүнең сәбәпләре турында сөйли.

СССР ның Текстиль Промышленносте Халык Комиссары иптәш **А. Н. Косыгин** текстиль промышленностеның эше һәм аның үсеш перспективалары турында сөйли. 1939 нчы елны производство планы үтәлде. Мамык белән тулысынча тәэмин ителгән предприятиеләрнең киләчәктә дә заданиеләрне үтәргә һәм арттырып үтәргә мөмкинлекләре бар. Текстиль предприятиеләренең саны һәм куәте өзлексез арта. Үткән елны гына да бар кадәр фабрикаларның куәте ун меңнәрчә орчыкка артты. Бу—8 яңа предприятие куәте белән бер тигез. Үткән елны СССР ның текстиль промышленносте дәүләт бюджетына 10.556 миллион сум бирде. Әгәр дә текстиль промышленносте югалтуларны киметсә һәм эшсез торуларны азайтса бу сума тагын да арткан булыр иде.

Депутат **А. Казакпаев** үзенең речендә төп игтибарны Казагстан ССР да терлекчелекне үстерү мәсьәләләренә юнәлдерә. Республикада терлекләр санын тагын да арттыру өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Ләкин халык хуҗалыгының бу тармагын тагын да үстерү өчен квалификацияле кадрлар—ветеринария врачлары, техник-терлекчеләр һ. б. хәзерләүне көчәйтергә кирәк.

Трибунада — Белоруссия ССР ның Гродно сайлау округыннан СССР Верховный Советына сайланган депутат **С. О. Притыцкий.** Ул үзен—социалистик Ватан, чын бәхет, чын тормыш тапкан кешене чолгап алган чиксез шатлык хисе турында сөйли.

— Минем хисләрем, алар—поляк капиталистларының һәм алпавытларының изүеннән батыр Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән 5 миллион белорус хезмәт ияләренең хисләре.

Депутат Притыцкий Сессия карамагына кертелгән бюджетның безнең Союзный республикаларыбызның экономик һәм культура үсеше интересларын чагылдыруын әйтә.

— Бюджетта Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләре өчен гаять зур сумалар билгеләнгән булуны ишетү минем өчен аеруча күңелле. Халыкның иң кирәкле ихтиаҗларына хәзерге вакытта Совет хөкүмәте бер ел эчендә бирә торган сумаларны элекке Польша дәүләте үзенең 20 ел яшәве чорында да бирә алмады.

— Белосток тукучылары үзләренең Белостокны икенче Ивановога әйләндерү өчен бөтен көчләрен бирәчәкләрен Верховный Советка белдерүне үтенделәр. Белостоктагы текстиль фабрикаларының, Гроднодагы тәмәке фабрикасының һәм Белосток өлкәсендәге башка предприятиеләрнең стахановчылары инде үзләренең сүзләрен намус белән җиренә җиткерәләр. Белосток тукучылары арасында күп станокларда эшләүчеләр хәрәкәте массовый төс алды. Белосток шәһәренең 1 нче текстиль комбинаты беренче квартал планын срогыннан алда үтәде. Совет власте айларында авыл хуҗалыгында да күп эшләр эшләнде. Беренче 40 колхоз төзелде. Беренче 24 машина-трактор станциясе оештырылды, яңа мәктәпләр ачылды, берничә өлкә театрлары эшли башлады.

Аннары депутат **М. И. Шевелев** чыга. Ул 1939 нчы елгы Арктика навигациясен үткәрүдәге уңышларны күрсәтеп үтә. Йөк ташу планы арттырып үтәлде. Йөк пароходлары барсы да зарарланмыйча портларга кайттылар. „Седов“ның героик экипажы Сталин заданиесен намус белән үтәде. 1940 нчы елны Төньяк диңгез юлы буенча йөк ташу планы 12 процентка үсә.

Депутат **В. К. Трутнев** СССР Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариатының эше турында тәнкыйть йөзеннән берничә сүз әйтә. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары әле сәламәтлек саклау мәсьәләләренә тиешенчә игтибар бирмиләр. Медицина учреждениеләреннән тулысынча файдаланылмый.

СССР ның Җиңел Промышленность Халык Комиссары **С. Г. Лукин** Ватаныбыздагы хезмәт ияләренең тормышы яхшыру белән киң куллану товарларына сорау һаман үсә бара,—ди. Җиңел промышленность работниклары алдында 1940 нчы елгы планны үтәүдән генә түгел, бәлки арттырып үтәүдән, халыкка өстәмә товарлар бирүдән, ә дәүләт бюджетына өстәмә сумалар бирүдән гыйбарәт булган мактаулы бурыч тора.

Депутат **Т. Мирзаев** үзбәк телендә сөйли. Ул 1940 нчы елгы бюджетка Ташкенттан Мельниково станциясенә кадәр тимер юл үткәрүгә хәзерлек һәм аны төзү өчен сума билгеләүне Сессиядән үтенә.

Депутат **И. Ю. Кравчук** Украинаның көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләреннән Совет властена кайнар рәхмәт тапшыра. Ул Дрогобычи өлкәсендәге дәүләт промышленность предприятиеләренең, аерым алганда нефть промышленностеның беренче уңышлары турында сөйли.

Депутат Кравчук реченнән соң Милләтләр Советының өченче утырышы ябыла.

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясе

ДЕПУТАТ ХАРИСОВ РЕЧЕ

(ТАТАРСТАН АССР НЫҢ БӨГЕЛМӘ ОКРУГЫ)

Депутат иптәшләр! Партиябезнең XVIII нче съездында иптәш Сталин докладында һәм бу съездның өченче бишьеллыкта халык хуҗалыгын үстерү турындагы карарларында хуҗалык, оборона һәм культура төзелешен тагын да үстерүнең гаять зур программасы билгеләнде, Совет Социалистик Республикалар Союзының политик һәм экономик бурычлары ачык һәм тирән итеп билгеләнде.

Совет дәүләтенең бюджеты партия һәм хөкүмәт кулында социалистик төзелеш эшенә средстволар туплауның әһәмиятле чыганагы.

Монда докладчы—депутат Зверев тарафыннан китерелгән саннар социалистик төзелешнең барлык участкыларында гаять зур җиңүләр барлыкны ачык күрсәтәләр. СССР ның бу җиңүләре союзный һәм автономияле республикалар бюджетларының системалы рәвештә үсүендә бигрәк тә ачык күренәләр.

1940 нчы елгы бюджетта халык хуҗалыгын үстерүгә, хезмәт ияләре массасының материаль һәм культура дәрәҗәсен тагын да күтәрүгә, куәтле Ватаныбызның оборона сәләтен ныгытуга сумалар бирүне тагын да үстерү күздә тотыла. Тынычлык политикасын үткәрү белән бергә, без, капиталистик чолганыш турында һәм империалистларның Советлар Союзы исәбенә үзләренең эчке каршылыкларын хәл итәргә омтылулары турында иптәш Сталин күрсәтмәләрен онытмыйбыз. Шуңа күрә дә без илебезнең оборона сәләтен ныгытуга бюджетта билгеләнгән 57 миллиард сум расходны бердәм рәвештә яклыйбыз.

Депутат иптәшләр! Коммунистик партиянең XVIII нче съезды бюджет-кредит эшен яхшыртырга, совет сумын ныгытырга кирәклекне күрсәтте. 1939 нчы елны финанс органнары финанс-налог эшен бер кадәр яхшыртуга ирештеләр. Ләкин шуның белән бергә күп кенә җитешсезлекләр дә бар әле.

Тәнкыйт тәртибендә, СССР Союзы Наркомфинының җирле бюджетларны үтәү белән канәгатьләнерлек шөгелләнмәвен күрсәтеп үтәргә тиешмен. Наркомфин работниклары җирле бюджетларның чын торышын белмиләр, Союз бюджетын үтәү белән генә шөгылләнәләр һәм шуңа күрә дә җирле бюджетларга караган күп кенә мәсьәләләр хәзергә кадәр хәл ителмичә калалар.

Саклык кассаларына вкладлар тарту дәүләтебезнең финанс куәтен ныгытуда әһәмиятле чыганакларның берсе. Татарстан республикасында, бөтен Советлар Союзындагы кебек үк, саклык кассаларындагы вкладлар елдан-ел үсәләр. 1937 нче елның 1 нче январена саклык кассаларында вкладлар 25 миллион сум булган булса, 1940 нчы елның 1 нче январена алар 48 миллион сумга җиттеләр. Ләкин әйтергә кирәк, бу өлкәдә безнең мөмкинлекләребез тулысынча файдаланылмыйлар әле. Саклык кассалары системасы әле һаман да канәгатьләнерлек эшләми. Наркомфин бу участкыга йомшак җитәкчелек итә. Дөрес, соңгы ике елда Союзда түбәнге саклык кассалары саны 14 меңгә артты. Ләкин бар урында да саклык кассалары массаның таләпләрен канәгатьләндерә алмыйлар, чөнки алар вкладчыларга якынайтылмаганнар. Ни өчен безнең эшчеләребез һәм хезмәткәрләребез үзләренең акчаларын кассага салу өчен ике-өч километр барырга тиешләр? Вкладчы үзенең акчаларын теләсә кай вакытта кассага кертә алсын өчен һәм моңа артык вакыт әрәм итмәсен өчен һәрбер завод, предприятие һәм учреждение янында саклык кассалары оештырырга ярамыймени? Бу катлаулы эш түгел һәм моны бик яхшы итеп оештырырга мөмкин.

1940 нчы елны саклык кассаларындагы вкладлар буенча зур гына сумма: 1 миллиард 800 миллион сум планлаштырыла. Бурыч җидди. Бу бурычны уңышлы хәл итү өчен саклык кассаларының эшен тамырыннан яхшыртырга, аларның структурасын үзгәртеп корырга кирәк. Мин, бу планны тайпылышсыз үтәүне тәэмин итү өчен чаралар эшләүне Наркомфинга һәм ВЦСПС ка тапшырырга кирәк дип саныйм.

Шулай ук МТС ларның финанс хуҗалыгы канәгатьләнерлек хәлдә булмавын да күрсәтеп үтәргә кирәк. Эш шунда, дәүләт бюджетыннан финанслауга күчү белән кайбер МТС работниклары эшне йомшарттылар. Финанс планнары МТС ларның производство программаларыннан аерылган хәлдә төзеләләр. МТС та директорның колхозлар белән исәп-хисап буенча урынбасары бар. Ләкин ни өчендер бу работниклар үзләренең эшләрен натуралата түләү белән генә шөгылләнүдән гыйбарәт дип саныйлар. Алар акча расчетлары белән шөгылләнүне кирәк тапмыйлар. Бу, минемчә, Наркомзем работникларының аларга юл куюларыннан килеп чыга торгандыр. Шуның белән бергә МТС лар натуралата түләү һәм колхозлар белән акча расчетлары буенча доходлар планын ничек үтәүләренә карамастан финансландырылалар. Һич шиксез, бу тәртиптә финанслаштырганда МТС директорлары үзләренең финанс хуҗалыклары белән кызыксынмыйлар, шуның нәтиҗәсендә 1939 нчы елгы бюджет колхозлар белән расчетлар буенча 102 миллион сум акчаны алып бетерә алмады.

Иптәш Зверев үзенең докладында, 1939 нчы елны күп кенә наркоматларның төзелешкә җибәрелгән средстволардан тулы файдаланмауларын, моның илебездә билгеләнгән төзелеш программасын үтәмәүгә китерүен күрсәтте. Мин, төзелешкә билгеләнгән лимитларны тулы үзләштерүгә тоткарлык ясаучы сәбәп, төзелеш проектларын төзүдәге һәм раслаудагы тоткарлыклардан, шулай ук техник документларның вакытында рәсмиләштерелмәвеннән гыйбарәт икәнлекне күрсәтергә тиешмен. Бу күренешне кискен рәвештә бетерергә кирәк.

Депутат иптәшләр! Потребкооперациянең нинди зур әһәмияте барлыгы сезгә билгеле. Безнең потребкооперациябездә яхшы эшләү һәм дәүләт бюджеты өчен доходларның шактый зур чыганагы булу өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Ләкин потребкооперациянең эшен яхшы дип әйтеп булмый. Потребкооперация системасында оборот средстволарын артык тоту зур булды. Мәсәлән, 1939 нчы елны оборотка карата товар югалтулар—0,51 процент булды. Растраталар дәүләткә шактый зур зиян китерәләр, аларның күләме зур. Центросоюз растраталарны бетерү өчен аеруча эшлекле чаралар кулланырга, оборот средстволарын артык тотуны минимумга кадәр киметелергә тиеш.

Депутат иптәшләр! Бюджетның кертелгән проекты 1940 нчы елны Советлар Союзы алдында тора торган хуҗалык-политик бурычларны уңышлы үтәүне тәэмин итә. Мин, СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджетын Бюджет Комиссиясе тарафыннан ясалган үзгәрешләре белән расларга кирәк дип хисаплыйм.

Һич шиксез, Ленин—Сталин партиясе һәм Совет хөкүмәте җитәкчелегендә, илебездәге хезмәт ияләренең киң массасы катнашы белән бюджет уңышлы үтәлер. (Кул чабулар).

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Башлангыч оешмаларда эш сыйфаты яхшыра

Биләр районында партиянең күпчелек башлангыч оешмалары отчет-сайлау җыелышларыннан соң үзләренең эшләрен сизелерлек рәвештә яхшырттылар. Партиянең эчке эшләре һәм хуҗалык мәсьәләләре белән җиддиерәк шөгелләнә башладылар. Мисаль өчен „Кызыл Октябрь“, Ленин һәм Сталин исмендәге колхозлар янындагы партия оешмаларын алырга мөмкин. Бу оешмаларда партия җыелышлары алдан яхшы хәзерлек белән, план буенча үткәрелә. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне тикшерүгә коммунистлар актив катнашалар. Элек чыгарылган карарларның үтәлеше һәм аерым коммунистларның партия поручениеләрен ничек үтәүләре турында партия җыелышында информацияләр тыңлау бу оешмаларның эш практикасына нык урнашып бара.

Партия оешмасының якыннан торып булышлык күрсәтүе нәтиҗәсендә, Ленин исмендәге колхоз язгы чәчүне яхшы хәзерлек белән каршылый. Бу колхозда кышкы агрономия чаралары тулысынча үтәлгән, авыл хуҗалыгы кораллары на ремонт күптән тәгәлләнгән һәм чәчү орлыклары тиешле кондициягә китерелгән. Колхозда ефремовчы звено төзелгән. Партия җыелышында ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе карарларын өйрәнгәннән соң оешмадагы коммунистлар производствоның аеруча җаваплы тармакларына беркетелгәннәр. Стена газетасы редакторлары, агитаторлар белән киңәшмә үткәрелгән һәм язгы чәчү чорында аларның бурычлары турында инструктаж ясалган.

Сталин исмендәге колхоз партоешмасы пропаганда эшенә зур игтибар бирә башлады. Отчет-сайлау җыелышларыннан соң үткән вакыт эчендә бу эшнең торышы партия җыелышында ике тапкыр тикшерелде. Шулай ук ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе карарлары, язгы чәчү вактында культура-масса эшләрен оештыру, „Ленин юлы“ колхозына фураж белән ярдәм итү һәм башка шундый мөһим мәсьәләләр партия җыелышларында тикшерелгәннәр. Партия оешмасы бу мәсьәләләр буенча җыелыш тарафыннан кабул ителгән карарларны үтәү өчен ныклы рәвештә көрәш алып бара.

Ләкин болар эшнең башлангычы гына әле. Отчет-сайлау җыелышы карарларын, ВКП(б) ның район һәм өлкә конференциясе карарларын тулы үтәү өчен партия оешмалары тагын да зуррак инициатива күрсәтергә тиешләр.

Б. Михайлов.

ВКП(б) ның Биләр райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

Казан машина-трактор мастерское эшчеләре СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе материалларын укыйлар.
А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КОММУНИСТЛАР АЛДА БАРАЛАР

Юдино районының Олы Яке авылындагы кандидатлар группасы моннан 10 ай элек оештырылган иде. Беренче көннәрдә группада ВКП(б) ның 3 кандидаты һәм 1 члены бар иде. Хәзер оешмада партия кандидатларының саны 20 гә җитә. Партиягә яңа алынучылар арасында район советы депутатларыннан 2 кеше һәм авыл советлары депутатларыннан 7 кеше бар.

Соңгы вакытларда партия кандидатларыннан кайбер иптәшләр җитәкче эшләргә күтәрелделәр. Район советы депутаты, „Маяк №1“ колхозы председателе иптәш Гәрәев район советы башкарма комитеты председателенең урынбасары булып, иптәш Шәһидуллин район советы башкарма комитетының гомуми бүлек мөдире булып эшлиләр. Элек колхоз склады мөдире булып эшләгән иптәш Шиһапов хәзер „Йолдыз № 3“ колхозы председателе итеп сайланды.

ВКП(б) кандидатлары колхоз производствосында авангард урынны алып торалар. Мәсәлән, ВКП(б) кандидаты, авыл советы депутаты иптәш Халитов авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясауда норманы һәр көнне 150 процент итеп үти. „Ярыш“ промартелендә каплар хәзерләүдә эшләүче иптәш Дәүләтшин айлык заданиене 140 процент үти. Иптәш Шиһапов җитәкчелек итә торган „Йолдыз № 3“ колхозы язгы чәчүгә үрнәк булырлык хәзерләнде.

ВКП(б) кандидатларының барсының да партия поручениеләре бар. Алар агитация-масса эше алып бару һәм колхозчылар арасында социалистик ярышны җәелдерү өчен аерым колхозларга һәм бригадаларга беркетелделәр.

„Йолдыз № 1“ колхозындагы барлык бригадаларда да стена газеталары чыгарыла. Агитаторлардан Клавдиева һәм Хәсәнова иптәшләр бригада стена газетасын 5 көнгә 1 тапкыр чыгарып баралар.

А. Насыйбуллин.

Кандидатлар группасы җитәкчесе.

КОМСОМОЛ ОЕШМАСЫ КОЛХОЗ ПРАВЛЕНИЕСЕНӘ ЯРДӘМ ИТӘ

Заинский районы, Урта Баграш авылы, „Марс“ колхозы янындагы комсомол оешмасы хуҗалык эшләре белән нык шөгылләнә. Язгы чәчүгә хәзерлектә колхоз правлениесенә зур булышлык күрсәтә.

Комсомол җыелышларында бригадирларның һәм турыдан-туры колхоз производствосында эшләүче аерым комсомолецларның информацияләре тыңлана. Көндәлек ярдәм итү нәтиҗәсендә, колхозның язгы чәчүгә хәзерлек эше шактый яхшырды. Аерым комсомолецлар бу өлкәдә аеруча үрнәк күрсәтәләр.

Мисаль өчен комсомолец иптәш Петров бригадасын алырга мөмкин. Аның бригадасында авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөрәҗәгате өйрәнелде. Бригада членнары арасында гектарыннан 100 пот иген уңышы алуга ирешү өчен көрәш җәелдерелде. Бригада членнарыннан Петров, Иванова, Петрова, Тазова иптәшләр агротехника чараларын тормышка ашыру өлкәсендә күпләргә үрнәк булып торалар.

Комсомол оешмасы атларны тәрбияләү һәм аларны язгы чәчүгә хәзерләү эшен яхшыртуны үз күзәтчелеге астына алды һәм бу тармакка аерым комсомолецлар беркетелде.

Колхозда стена газетасы яхшы гына эшләп килә. Стена газетасында стахановчыларның эш тәҗрибәләре, язгы чәчүгә хәзерлектәге уңышлы яклар һәм кимчелекләр системалы рәвештә яктыртып барыла.

Л. Максимов.

ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫНДА

I. Фән, хәрби белем, уйлап табу, әдәбият һәм сәнгат өлкәсендәге күренекле хезмәтләр өчен Сталин исмендәге премияләрне бирү тәртибе турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы фән, хәрби белем, уйлап табу, әдәбият һәм сәнгат өлкәсендәге күренекле хезмәтләр өчен Сталин исмендәге премияләрне бирү тәртибен раслады.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советының 1939 нчы ел, 20 нче декабрь һәм 1940 нчы ел 1 нче февраль карарлары белән Сталин исмендә билгеләнгән премияләр фән, хәрби белемнәр һәм уйлап табу буенча Сталин исмендәге премияләр комитетының һәм әдәбият, сәнгат буенча Сталин исмендәге премияләр Комитетының күрсәтүе белән ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы тарафыннан ел саен бирелә. Бу комитетлар фән, хәрби белемнәр, уйлап табу, әдәбият һәм сәнгат өлкәсендәге Сталин исмендәге премиене алуга билгеләнә торган хезмәтләрне алдан карау өчен ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы янында төзеләләр.

Фән, хәрби белемнәр, әдәбият һәм сәнгат өлкәсендәге хезмәтләр, шулай ук уйлап табуларның заявкылары яки аларның аңлатма язулары һәм шуларга Сталин исмендәге премиене алуга кирәк булган барлык документлар ел саен 15 нче октябрьдән дә соңга калмыйча Сталин исмендәге премияләр комитетларына бирелә, комитетлар аларны премиене бирү турындагы тәкъдим белән берлектә 1 нче декабрьдән дә соңга калмыйча ССР Союзы Халык Комиссарлары Советына тапшыралар.

Сталин исмендәге премиене алуга бары тик премие бирелә торган елда тәмам булган яңа хезмәтләр яки уйлап табулар гына кертелә. Хезмәтләрне яки уйлап табуларны фән җәмгыятьләре, фәнни тикшеренү институтлары, югары уку йортлары һәм җәмагать оешмалары кертә алалар.

15 нче октябрьдән 31 нче декабрьгә кадәр булган вакыт арасында тәмам булган хезмәтләр яки уйлап табулар Сталин исмендәге премиене алуга алдагы елда кертелә алалар.

Фән һәм хәрби белемнәр өлкәсендәге хезмәтләр һәм уйлап табу турындагы язмалар 3 данә итеп язу машинасында яки типографиядә бастырылып, теләсә нинди телдә тапшырылырга мөмкин; әдәби, музыкаль әсәрләр һәм архитектура корылмалары проектлары бер данәдә тапшырылалар, ә сәнгатьнең башка төрле әсәрләре—төп оригиналларында тапшырылалар.

Театр сәнгате һәм кинематография өлкәсендәге хезмәтләргә бәя бирү һәм премияләр бирү кертелгән материаллар (пьесалар, сценарийлар, макетлар һ. б.) нигезендә дә, шулай ук инде күрсәтелгән кинофильмнәр һәм театр постановкалары нигезендә дә үткәрелә.

Фән, хәрби белемнәр, уйлап табу, әдәбият һәм сәнгат өлкәсендәге күренекле хезмәтләр өчен Сталин исмендәге премияләрне бирү турында ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карарлары 21 нче декабрь көнне үзәк матбугатта игълан ителәләр. Сталин исмендәге премиене алган кешеләргә диплом бирелә.

Фән, хәрби белемнәр һәм уйлап табу буенча Сталин исмендәге премияләр Комитетын СССР Халык Комиссарлары Советы түбәндәге составта раслады:

Комитетның председателе—академик А. Н. Бах, председательнең урынбасарлары — 1) академик Т. Д. Лысенко, 2) югары мәктәпләр буенча Бөтенсоюз Комитеты Председателе С. В. Кафтанов, Комитетның членнары: А. И. Абрикосов, А. А. Байков, А. А. Богомолец, Е. С. Варга, А. Г. Вовко, Б. Н. Веденисов, К. В. Горев, В. А. Дегтярев, А. Ф. Иоффе, Т. Кара-Ниязов, А. К. Коленковский, В. Л. Комаров, Г. П. Косяченко, А. Н. Крылов, В. В. Кузнецов, Н. С. Курнаков, М. Н. Логинов, Я. А. Манандян, В. А. Меликов, М. Б. Митин, Н. И. Мусхелишвили, В. А. Обручев, Л. А. Орбели, В. А. Петровский, П. Н. Поспелов, В. П. Потемкин, С. П. Ставицкий, Е. В. Тарле, И. П. Трайнин, А. А. Чернышев, Е. А. Чудаков, О. Ю. Шмидт, А. С. Яковлев, Е. М. Ярославский.

Әдәбият һәм сәнгат буенча Сталин исмендәге премияләр Комитетын СССР Халык Комиссарлары Советы түбәндәге составта раслады:

Комитетның председателе—СССР ның халык артисты В. И. Немирович-Данченко,

председательнең урынбасарлары—1) Р. М. Глиэр, 2) М. А. Шолохов, 3) А. П. Довженко. Комитетның членнары: Н. Н. Асеев, Г. Ф. Александров, А. В. Александров, Куляш Байсәитова, И. Г. Большаков, В. А. Веснин, И. Э. Грабарь, А. Б. Гольденвейзер, А. М. Герасимов, А. С. Гурвич, У. Хаҗибеков, А. К. Гулакян, И. О. Дунаевский, Янка Купала, Е. М. Кузнецов, А. Е. Корнейчук, И. К. Луппол, В. И. Мухина, С. Д. Меркулов, Абдылас Молдыбаев, А. Г. Мордвинов, И. М. Москвин, С. М. Михоэлс, Н. Я. Мясковский, Хәлимә Насыйрова, С. А. Самосуд, Р. Н. Симонов, И. Я. Судаков, А. Н. Толстой, А. А. Фадеев, М. Б. Храпченко, А. А. Хорава, М. Э. Чиаурели, Н. К. Черкасов, Ю. А. Шапорин, Ф. М. Эрмлер.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Сталин исмендәге премияләр буенча ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы янындагы югарыда күрсәтелгән Комитетлар турындагы положениене раслады.

II. Сталин исмендәге стипендияләрне билгеләү тәртибе турында

1. ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы **фәннәр докторы һәм фәннәр кандидаты** дәрәҗәсенә диссертация яклауга хәзерләнүче кешеләр өчен Сталин исмендәге стипендияләрне билгеләү тәртибе турындагы положениене раслады.

Бу положение буенча, фәннәр докторы дәрәҗәсенә диссертация яклауга хәзерләнүчеләр өчен ССР Союзы Совнаркомының 1939 нчы ел, 20 нче декабрь карары белән СССР Фәннәр Академиясендә Сталин исмендә оештырылган стипендияләрне алу хокукы СССР Фәннәр Академиясенең фәнни тикшеренү институтларының яки башка төрле фәнни тикшеренү институтларының һәм югары уку йортларының фән сотрудниклары арасыннан да, шулай ук башка гражданнар арасыннан да үзләрен фәнни хезмәтләре белән күрсәткән кешеләргә бирелә.

Фәнни эшкә хәзерләнүче һәм фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклауга хәзерләнүче кешеләрдән Сталин исмендәге стипендия алу хокукы фәнни тикшеренү институтларының һәм югары уку йортларының иң яхшы аспирантларына һәм фән работникларына, шулай ук башка гражданнарга бирелә.

Сталин исмендәге стипендияне алуга кандидатларны фәнни тикшеренү институтларының һәм югары уку йортларының советлары күрсәтәләр. Стипендияне персональ төстә билгеләү СССР Фәннәр Академиясе Президиумының һәм ССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитетының берләштерелгән утырышында үткәрелә.

Фәнни тикшеренү институтларының һәм югары уку йортларының советлары Сталин исмендәге стипендияләрне алуга билгеләнгән кандидатларның исемлекләрен ел саен 1 нче майдан да соңга калмыйча тапшыралар. Стипендияне алуга билгеләнгән кандидатлар 1 нче июньнән дә соңга калмыйча расланалар. Стипендия түләү раслану көненнән башлана.

Сталин исмендәге стипендия алуга билгеләнгән кешеләрнең исемлекләре „Вестник Академии наук“ та һәм СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитеты „Бюллетене“ ндә игълан ителәләр.

Фәнни тикшеренү институтларының һәм югары уку йортларының советлары тарафыннан стипендиядән мәхрум итү бары тик СССР Фәннәр Академиясенең һәм СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп комитетының раславы белән генә булырга мөмкин.

2. ССР Союзы Совнаркомы шулай ук **югары уку йортлары укучыларына** Сталин исмендәге стипендияне билгеләү турындагы положениене дә раслады.

Бу положение буенча Сталин исмендәге стипендияләр югары уку йортларының аеруча күренекле отличник студентларына бирелә.

Сталин исмендәге стипендияне алуга кандидатларны югары уку йортларының советлары күрсәтәләр.

СССР ның Халык Комиссариатлары карамагындагы, шулай ук СССР Совнаркомы янында алар белән бер дәрәҗәдәге үзәк учреждениеләр карамагындагы югары уку йортларының укучыларына стипендияләрне халык комиссарлары һәм тиешле үзәк учреждениеләрнең җитәкчеләре билгелиләр.

Стипендияләрне түләү һәр елның 1 нче июлендә башлана. 1940 нчы елны стипендияләр түләү 1940 нчы елның 1 нче январеннан башлана.

Союзный республикалар карамагындагы югары уку йортларының укучыларына стипендияләрне союзный республикаларның совнаркомнары билгелиләр.

Сталин исмендәге стипендияләрне СССР ның Халык Комиссариатлары арасында һәм СССР Совнаркомы янында алар белән бер дәрәҗәдәге үзәк учреждениеләр арасында, шулай ук союзный республикалар арасында бүлүне СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитеты башкара һәм аннары ул ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы тарафыннан раслана.

Сталин исмендәге стипендиягә билгеләнгән студентларның исемлеге СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитетының „Бюллетене“ ндә игълан ителә.

Югары уку йортларының укучыларын Сталин исмендәге стипендиядән мәхрум итү бары тик тиешле халык комиссарының яки союзный республика совнаркомының раславы белән генә булырга мөмкин.

Югары уку йортларының укучыларына Сталин исмендәге стипендияне билгеләү тәртибе турындагы положениене раслау белән бер үк вакытта, ССР Союзы Совнаркомы бу стипендияләрне 1939—40 нчы уку елында СССР ның халык комиссариатлары арасында һәм СССР Совнаркомы янында алар белән бер дәрәҗәдәге үзәк учреждениеләр арасында, шулай ук союзный республикалар арасында бүлү буенча СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитеты тарафыннан кертелгән планны раслады. (ТАСС).

„Правда“, 2 апрель.

Язгы чәчү алдыннан

ЯХШЫ ХӘЗЕРЛЕК

Язгы чәчүне уңышлы хәл итү— ул, югары иген уңышы яулап алу өчен көрәшнең нигез шартларыннан берсе. Тымытык районының Киров исмендәге авыл хуҗалыгы артеле членнары бу бик җаваплы эшне уңышлы башкару өчен үрнәкле рәвештә хәзерләнделәр.

Биредә кышкы агротехника чаралары тулысынча үткәрелгән. 15.000 йөк урнына 19 мең йөк тирес чыгарылган. Башка ашламалар планы да артыгы белән үтәлгән. Агротехника түгәрәкләрендә 30 кеше укып чыккан. Һәрбер культура буенча орлык җитәрлек хәзерләнгән.

Колхоз авыл хуҗалыгы машиналарын, инвентарьны ремонтлау эшен күптән төгәлләде. Һәрбер бригадада арба, камыт һәм башка инвентарь җитәрлек. Бригадалардагы атлар группаларга бүленгән, аларга аерым тәрбия оештырылган. Колхозда бер генә дә ябык ат юк.

Һәрбер бригадада даими звенолар төзелгән. Колхозның производство планы һәм чәчү вакты өчен эш планы бригадаларга, звеноларга җиткерелгән. Колхозның язгы чәчү мәйданы 100 проценты белән тунга сөреп калдырылган.

Бөртекле һәм кузаклы культураларны чәчү срогы 6—7 көн итеп билгеләнә.

— Без быел—ди агротехник иптәш Нуреттинов — орлыкны яровойлаштырып чәчүгә зур игтибар бирәбез. Шакмаклап чәчү киң кулланылачак. Тәҗрибә моның гүзәл нәтиҗәләр бирүен күрсәтте.

Иптәш К. Нуреттинов бригадасы үткән ел шакмак тәртиптә чәчкән 49 гектар мәйданның һәрбер гектарыннан 13 әр центнердан артык бодай алган. Ә мульчирование үткәргән 3 гектарда уңыш гектарына уртача 22,7 центнер булган.

Быел 380 гектар бодай тулысынча яровойлаштырылып чәчеләчәк. Шуның 200 гектары шакмак тәртиптә чәчеләчәк. 20 гектар мәйданда мульчирование үткәреләчәк. Моның өчен җитәрлек күләмдә пычкы чүбе хәзерләнгән. Орлык яровойлаштыру өчен 20 кеше сайлап алынган. Орлык яровойлаштыру һәм агулау өчен урын һәм кирәкле инвентарьлар хәзер.

Киров исмендәге колхоз чәчүгә әнә шулай хәзерләнә. Хәзер звенолар үз участкыларында кар суын саклап калу эше белән шөгылләнәләр. Әхметшин Вәли, Ногманов Гаяз, Закиров Хәйрулла һәм башка иптәшләр чәчү техникасын өйрәнәләр. Алар чәчүнең югары сыйфатын тәэмин итү, көнлек норманы арттырып үтәү буенча конкрет йөкләмәләр алып, үзара социалистик ярыш договоры төзеделәр. *Салахеттинов.*

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты СВОДКАСЫ

(Планга карата процентларда)

1940 нчы елның 1 нче апреленә

МТС лар	Үтәлеш
Төньяк районнар.	
Нөркәй	100,0
Теләче	100,0
Маткавыш	100,0
Актаныш	100,0
Мөслим	100,0
Янил	100,0
Алга	100,0
Кадрәк	100,0
Тирсә	100,0
Т. Тамак	100,0
Минзәлә	100,0
Азин	100,0
Балтач	100,0
Чаллы	100,0
Кукмара	97,9
Бондюг	93,0
Исәнбай	92,2
Калинин	88,9
Саба	88,6
Этнә	86,0
Тәкәнеш	85,7
Арча	85,3
Морт	85,1
Балык Бистәсе	84,2
Мамадыш	83,3
Кызыл Юл	76,0
Кызыл Йолдыз	76,4
Алабуга	74,5
Димитровский	60,6
Барлыгы	91,0
Көньяк-көнчыгыш районнар:	
Тымытык	100,0
Әлмәт	100,0
Беренче Май	100,0
Сарман	100,0
Чаллы	100,0
Кичү	100,0
Шөгер	98,0

МТС лар	Үтәлеш
Ютазы	96,3
Иске Писмән	92,6
Кәкре Елга	90,9
Чыбыклы	86,5
Акташ	85,2
Чишмә	83,3
Баулы	78,1
Соколка	77,8
Поповка	77,6
Үзәк	76,9
Бөгелмә	70,7
Заинский	64,7
Кузайкино	63,5
Карамалы	61,2
Барлыгы	85,6
Кама арты районнары:	
Черемуховский	100,0
Иске Чишмә	100,0
Аксубай	100,0
Кызыл Чапчак	100,0
Октябрь	98,2
Зур Поляна	97,6
Чистай	96,7
Куйбышев	94,0
Мөслим (Чистай)	91,7
Зирекле	90,2
Кузнечиха	87,0
Әлки	86,0
Биләр	85,1
Иске Тимошкино	82,9
Трехозерский	80,0
Базарлы Матак	79,6
Салман	79,4
Алексеевский	77,3
Каргалы	76,8
Чиябаш	74,5
Тат. Ялтан	74,1
Яңа Чишмә	73,3
Кошкинский	72,5

МТС лар	Үтәлеш
Тельман	66,0
Ромадан	65,9
Барлыгы	84,8
Көнбатыш районнар:	
Кама Тамагы	100,0
Юртыш	100,0
Дәүләки	100,0
Чүпрәле	100,0
Тархан	97,7
Буденный	96,4
Ишеево	94,1
Олы Кариле	91,7
Столбище	90,9
Норлат	89,1
Буа	88,4
Мәлки	87,5
Майдан	87,1
Тәтеш	86,5
Әлши	85,7
Биектау	84,9
Тат. Ходяш	83,0
Макыл	82,4
Питрәч	82,3
Мөрәле	81,6
Юдино	80,9
Әхмәмәт	77,8
Чүрибураш	77,4
Дөбъяз	74,1
Константиновский	68,7
Рождественский	62,3
Чокалы	58,2
Зөя	41,1
Барлыгы	83,3
Барлык МТС лар буенча	86,1
1940 нчы елның 25 нче мартына	82,6
1939 нчы елның 1 нче апреленә	90,6

Чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейдә

(Үз хәбәрчеләребездән һәм ТатТАСС хәбәрләреннән)

ЗУР ҖИТЕШСЕЗЛЕКЛӘРНЕ АЧАЛАР

ШИРӘМӘТ, 3 апрель. (ТатТАСС). Ширәмәт районының эшче - авыл хәбәрчеләре колхозларның чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү рейденә актив катнашалар. Һәрбер колхозда эшче - авыл хәбәрчеләре бригадалары төзелде. Авыл хәбәрчесе иптәш Шетнев җитәкчелегендәге бригада „13 лет Октября" колхозының чәчүгә хәзерлеген тикшерде. Колхозда күп кенә җитешсезлекләр барлыгы беленде. Колхоз агротехника чараларын, кар тоту, тирес чыгару һәм көл җыю планын үтәмәгән.

„Болгар" колхозында да эшче-авыл хәбәрчеләре рейде күп кенә кимчелекләрне ачты. Мәсәлән, 60 центнер чәчүлек орлык чистартылмаган. 483 центнер орлыкның бары 160 центнеры гына яхшы сыйфатлы. Башка орлыкларның тишелеше тикшерелмәгән. Чәчү машиналарына ремонт төгәлләнмәгән. Кар тоту, көл җыю һәм кош тизәге җыю планы үтәлмәгән. Звенолар формаль рәвештә генә төзелгәннәр. Колхозның производство планы колхозчыларның гомуми җыелышында расланмаган. Социалистик ярыш договоры төзелмәгән. Колхоз председателе иптәш Яруллин югары иген уңышы алу өчен көрәшкә җитәкчелек итмәгән.

Рейд йомгаклары һәм эшче-авыл хәбәрчеләре бригадаларының такдимнәре колхоз правлениесе утырышында һәм колхозчыларның гомуми җыелышында тикшерелде. Кимчелекләрне ашыгыч рәвештә бетерү буенча чаралар күрелде. 3 нче апрельдә „Болгар" колхозы вәкилләре социалистик ярыш договоры төзү өчен „Алга" колхозына киттеләр.

Орденлы Актаныш МТС ының стахановчы-токаре иптәш П. Ляпустин. Ул айлык планны системалы рәвештә 200 процентка үти. Иптәш Ляпустин республика Почет Тактасына кертелде.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

БРИГАДАЛАР ЭШКӘ КЕРЕШТЕЛӘР

Партиянең Акташ райкомы һәм район газетасы редакциясе колхозларның чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү буенча эшче - авыл хәбәрчеләреннән 20 бригада оештырдылар.

Иптәш Хәбибуллина бригадасы „Якты Юл" колхозында чәчүгә хәзерлекне тикшерде. Тикшерү колхозның чәчүгә хәзер икәнлеген күрсәтте. Колхозда 18 звено оештырылган. Һәрбер звеноның эш планы бар.

Иптәш Штаев бригадасы Чумаков исмендәге колхозны тикшерде. Монда чәчүгә хәзерлектә кимчелекләр бар. Чәчүлек ясмык орлыгы саклангаң амбарның түбәсеннән су үтә. 76 баш атның көрләге уртадан түбән. Колхоз председателе иптәш Филюшин бу кимчелекләрне бетерү өчен чаралар күрми.

Тикшерү йомгаклары колхоз правлениесе утырышында каралды. Колхоз правлениесе бригада тарафыннан ачылган барлык кимчелекләрне бетерү буенча ашыгыч чаралар күрү турында карар кабул итте.

ТИКШЕРҮНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ӨЙРӘНЕЛӘ

Буа районында эшче-авыл хәбәрчеләреннән төзелгән 80 бригада колхозларның язгы чәчүгә хәзерлекләрен тикшерә.

Коминтерн исмендәге колхоз язгы чәчүгә яхшы хәзерләнгән. Колхоз кондициягә җиткерелгән чәчүлек орлыклар белән тәэмин ителгән. Атларның торышы яхшы. Эш планнары төзелгән һәм звеноларның эше тәртипкә салынган.

Киров исмендәге колхоз да чәчүгә яхшы хәзерләнгән. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм сбруйларга ремонт ясалган. 1 нче апрельдән башлап атлар ялга куелдылар. Атларга һәр көнне 6 килограмм концентрат бирелә. Колхоз ашханә һәм балалар яслесе ачарга хәзерләнә.

Сталин исмендәге, „Красная Армия" һәм „Кызыл Йолдыз" колхозларында җитди кимчелекләр барлыгы беленде. Сталин исмендәге колхоз кондициягә җиткерелгән чәчүлек орлыклар белән 68 процент кына тәэмин ителгән. Производство планнары һәм МТС белән договор төзелмәгән. Атлар аерым карауччыларга беркетелмәгәннәр.

Бу колхозда тикшерү нәтиҗәләре партия оешмасы җыелышында һәм колхоз правлениесе утырышында каралды. Хәзер язгы чәчүгә хәзерлектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрелә. Чәчүлек орлыклар тәүлек буена чистартылалар. Стена газеталарының махсус номерлары чыгарыла.

БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР

Минзәлә районы колхозларында колхозларның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде башланды. Киров исмендәге колхозның авыл хәбәрчеләре рейдне беренче булып үткәрделәр. 3 кешедән төзелгән бригада Киров исмендәге колхозның чәчү орлыклары белән тулысынча тәэмин ителгәнлеген күрсәтеп үтте.

Колхоз правлениесе барлык машиналар язгы чәчүгә хәзерләнгән дип хисаплый. Ләкин авыл хәбәрчеләре бу машиналарда күп кенә кимчелекләр барлыкны ачтылар. Ремонт ясалган 3 чәчкечнең 2 се канәгатьләнерлек хәлдә түгел. Бер чәчкечтә дисклар өчен пружиналар, икенчесендә орлык үткәргечләре юк. Колхозда атларны тәрбияләү эшендә иясезлек тудырылган. Барлык атларга өч ат караучы бергәләп хезмәт күрсәтә. 4 баш атның көрлеге уртадан түбән.

Авыл хәбәрчеләре күп кенә кимчелекләрне ачтылар. Колхозчылар язгы чәчүдә үзләренең нәрсә эшләргә тиеш икәнлекләрен белмиләр. Звенолар формаль рәвештә генә төзелгәннәр. Ул гына да түгел, язгы чәчүдә звенолап эшләүне монда бөтенләй планлаштырмыйлар.

„Красный партизан", „Луч", „Буденновец", „Наш труд" һәм Чапаев исмендәге колхозларда да авыл хәбәрчеләре рейдләре башланды.

„Красный партизан" колхозында атларны яхшы тәрбиялиләр. Беренче бригаданың ат караучысы иптәш Митюшкин, 4 нче бриганың ат караучылары Кочнев һәм Гуничев һәм 5 нче бригаданың ат караучысы Буглеев иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Бу колхозда авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт югары сыйфатлы итеп үткәрелгән. Барлык машиналар бригадирларга актлар белән тапшырылганнар. Ләкин монда да кимчелекләр барлыгы беленде. Бригадаларның һәм бөтен килеш алганда колхозның производство планнары әле һаман колхозчыларның җыелышларында расланмаганнар.

Чапаев исмендәге колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшергән авыл хәбәрчеләре бригадасы бу колхозның язгы чәчүгә нигездә хәзерләнгәнлеген күрсәтеп үтте. Машиналар барсы да ремонттан чыккан. Колхозның һәм бригадаларның производство планнары төзелгән һәм алар колхозчыларның гомуми җыелышларында расланганнар.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә. Рәсемдә: яшелчәләр теплицасында.

А. Иаселевич фотосы (ТАСС фото-хроникасы).

ТАТАРСТАН ПРОМЫШЛЕННОСТЕНЫҢ БЕРЕНЧЕ КВАРТАЛДАГЫ ЭШЕ ТУРЫНДА СВОДКА

Җиңел промышленность предприятиеләре буенча:

(План үтәлеше процентларда)

1 нче тегү фабрикасы	105,0
2 „	109,4
4 „	115,7
5 „	116,4
6 „	110,1
„Кызыл Тукучы" фабрикасы	94,5
Киез итек-фетр фабрикасы	106,2
Ленин исмендәге кун заводы	122,1
„Кызыл күнче" заводы	120,3
Чистай кун заводы	100,0
„Спартак" комбинаты	102,6
Аерым заказлар буенча аяк киемнәре эшләү фабрикасы	104,5
Кун-галантерея фабрикасы	101,8
Шорный фабрика	102,3
Сукно фабрикасы	91,7
Мамык фабрикасы	101,1
Җирле промышленность предприятиеләре буенча:	
Язу машиналары заводы	92,5
„Красный путь" заводы	90,1
Татметровес	108,6
Пыяла заводы	80,0
Татполиграф	82,3
Гармон фабрикасы	82,2
Галантерея фабрикасы	111,8
Азык промышленносте предприятиеләре буенча:	
„Кызыл шәрык" заводы	112,5
Микоян исмендәге кондитер фабрикасы	58,7
Мальтозный завод	165,8
Уксус заводы	110,4
Макарон фабрикасы	80,5
Казандагы саго заводы	66,8
Лаештагы саго заводы	168,4
Мехкомбинат предприятиеләре буенча:	
1 нче фабрика	105,2
2 „ „	97,3
3 „ „	94,9
4 „ „	113,4
ФЗУ мәктәбе	102,0
Утиль заводы	100,0
Механика заводы	118,3
Ленин исмендәге җитен комбинаты буенча:	
Тарау фабрикасы	69,3
Эрләү фабрикасы	80,0
Туку фабрикасы	73,0
Отделка цехы	73,0
Тегү фабрикасы	54,0

Академик Т. Д. ЛЫСЕНКО

ЯРОВАЙЛАШТЫРУ ТУРЫНДА

Сабан бодаен, арпаны һәм солыны иртә һәм кыска срокларда чәчү өчен көрәшкә партия һәм хөкүмәт зур игтибар бирәләр.

Сабан ашлыгының яровойлаштырылган орлыклары аеруча иртә һәм бердәм булып тишелүнең сәбәбе шунда: орлыклар инде чәчкәнгә кадәр үк бүрткән булалар, аларда ферментларның эше көчәя, эреми торган туклыклы маддәләрнең эри торган туклыклы маддәләргә күчүләре башланган була. Орлыкларның яралгылары җинелчә генә үсә башлыйлар, ләкин үсеш бик кечкенә була, ул әле орлык кабыгын ярып чыгарлык хәлдә дә булмый; шулай ук тамыр калкулары (булачак тамырлар) да үсә башлыйлар, ләкин әле алар күзгә күренерлек булып үсмәгән булалар. Гомумән, орлыклар шундый хәлгә китерелгән булалар ки, әйтик, әгәр дә алар яхшы хәзерләнгән туфракка иртә белән чәчелсәләр, еш кына инде кич белән тамыр җибәрәләр, ә бер тәүлектән тамырлары шактый ныгый.

Моның үзеннән генә дә инде агрономнарга, колхозчыларга һәм совхоз работникларына бөртекле сабан ашлыгын яровойлаштырып чәчүнең өстенлекләре бик ачык аңлашылырга тиеш. Узган елларда колхозларда һәм совхозларда миллионнарча гектар җиргә яровойлаштырылган орлыклар чәчү практикасы күрсәткәнчә, агрономиянең бу чарасын куллану үзен аклады. Гадәттә чәчүлек материалны яровойлаштыру өчен тотылган һәрбер хезмәт көненә кимендә 2 центнер өстәмә уңыш алу килә.

Иртә чәчелә торган сабан культураларын чәчү вактын берничә көнгә кыскарту районның, шулай ук аерым колхозның зур казанышы дип санала. Яровойлаштырылган орлыклар белән иртә, кыскартылган срокларда чәчкәндә алар берничә көн элек һәм аеруча бердәм булып тишелеп чыгалар, аларның тамыр системасы яхшы була, минем карашымча, бу да районнарның һәм колхозларның казанышлары булып саналырга тиеш.

Яровойлаштырылган чәчүлекләр үткәрү өчен көрәш—ул яхшы эшкәртелгән туфракка бөртекле ашлыкларны аеруча иртә язгы чәчү өчен көрәшү белән бер.

Яровойлаштыруны кулланганда, аеруча иртә һәм бердәм булып тишелеп чыгуга ярдәм итә торганнарның барсын да эшләргә омтылырга кирәк, шул ук вакытта чәчүлек материалны бозылу куркынычыннан сакларга кирәк.

Колхозлар һәм совхозлар 1940 нчы елны яровойлаштыруны куллану турындагы мәсьәләне узган еллардагы производство тәҗрибәсе нигезендә хәл итәргә тиешләр.

Күп кенә төп бөртекле ашлык районнарында соңгы 5 ел эчендә яровойлаштырылган чәчүлекләр бөртекле сабан ашлыгы чәчүлекләренең 50 процентган күбрәк мәйданнарында үткәрелде һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирешелде. Бу районнарда, узган еллардагы нәтиҗәләргә анализ ясау нигезендә, 1940 нчы елны яровойлаштыруны агрономия алымы сыйфатында производство масштабларында файдаланырга кирәк.

Яровойлаштыруны киң күләмдә куллануда иң кыен момент—ул, чәчү материалын чылатуны башлау вактын сайлау. Яз иртә килгән елларда бу бигрәк тә кыен була, чөнки мондый елларда суыклар яңадан башланучан була һәм кыр эшләре тукталып кала. Соңырак килгән яз гадәттә бердәм була. Ләкин бу хәлдә дә яровойлаштыру өчен орлыкларның һәрбер партиясенең кайчан чәчеләчәген реаль исәпкә алып, орлыкларны чылата башлау срогын сайлау эшенә саклык белән генә якын килергә кирәк.

Яровойлаштыру буенча 1937 нче елны чыгарылган инструкциядә, шулай ук СССР Наркомземы тарафыннан быел чыгарылган плакатта болай диелә: „Соң өлгерә торган каты бодайны, шулай ук сабан арпасын һәм солыны яровойлаштыруны кыр эшләре (туңга сөрелгән җирләрне тырмалау) башланудан кимендә 3—5 көн элек башларга кирәк".

Йомшак сортлы язгы бодай, һәм иртә өлгерә торган каты бодай өчен дә күрсәтмә бар: „Яровойлаштыру срогы әле төгәлләнмәгән булса да, яровойлаштырылган орлыкны чәчүнең беренче көннәрендә үк тезмә чәчкечләр белән чәчәргә, йомшак сортлы язгы бодайны һәм иртә өлгерә торган каты бодайны яровойлаштыруны кыр эшләре (туңга сөрелгән җирләрне тырмалау) башланудан 1—3 көннән дә элек башламаска кирәк".

Шуны әйтергә кирәк, орлыкларны чылатуга күрсәтелгән сроклардан элек керешергә һич тә ярамый. Бу күрсәтүне үтәмәү яровойлаштырылган чәчү материалының чәчүгә кадәр озак ятуы мөмкин һәм суыклар яңадан башлана калса яки хуҗалыкта нинди дә булса уңайсызлык (җир хәзер булмау һ. б.) килеп чыкса ул орлыкларны чәчү мөмкин булмаячак.

Мондый орлыклар, яровойлаштыруның 5—7 нче көнендә чәчелгән йомшак сорт бодай орлыклары кебек үк бердәм һәм иртә тишелеп чыга алмыйлар.

Шулар нигезендә, 1940 нчы елны яровойлаштыру планын төзегәндә һәрбер колхозда һәм совхозда бер көнне күпме җиргә чәчүне дә исәпкә алырга кирәк. Яровойлаштыру өчен орлыкларны чылатканда аның күләме хуҗалыкта бер көндә чәчү өчен кирәк булганнан артык булмаска тиеш.

Теге яки бу сәбәп белән вактында чәчү мөмкин булмаганлыктан, яровойлаштырудан соң озак яткыруга караганда, яровойлаштырылып җитмәгән орлыкларны чәчү хуҗалык ягыннан файдалырак, моны истә тотарга кирәк. Тәҗрибә күрсәткәнчә, йомшак сорт бодай һәм иртә өлгерә торган каты бодай яровойлаштыруда 5—7, ә арпа һәм солы 10—14 көн тотылса бигрәк тә яхшы була.

Узган елларда, миллионнарча гектар җиргә чәчү өчен колхозларда һәм совхозларда яровойлаштыру кулланганда, мәйданнарның күпчелегенә күрсәтелгән срокларда яровойлаштырылган орлыклар чәчелде, дип әйтергә мөмкин. Ләкин күп кенә мәйданга, инструкциядә такдим ителгәнгә караганда озак яткырылган орлыклар чәчелде. Бу шундый хәлләрдә булды, колхозларда һәм совхозларда яровойлаштыру өчен орлыкларны чылату эшенә бик иртә керештеләр яки аларны бер көндә шул кадәр күп чылаттылар ки, хуҗалык аларны көнендә чәчеп өлгерә алмады. Күп кенә мәйданга чылатудан соң 2—3 көн генә торган орлыклар да чәчелде; бу орлыклар яровойлаштыруда инструкциядә күрсәтелгәнгә караганда азрак яттылар.

Хуҗалык шартларында, яз көне яровойлаштыру өчен билгеләнгән орлыкларның һәрбер партиясен чәчү көнен алдан ук дөрес итеп билгеләп кую кыен. Шуңа күрә дә чәчүлек материалны чылату срогын билгеләгәндә, түбәндәгеләрдән чыгып эш итәргә кирәк: һава начар булганлыктан яки чәчү өчен кырлар өлгермәгәнлектән яровойлаштырган вакытта орлыкларны инструкциядә күрсәтелгән сроклардан озагырак тотуга караганда, яровойлаштыру срокларының ахрына кадәр җиткерелмәве яхшырак була.

Колхозлар һәм совхозлар яровойлаштырылган һәм төрле дәрәҗәдәге яровойлашып җитмәгән, ягни чылатылган орлыклар белән чәчүне планлаштырырга тиешләр. Ләкин яровойлаштыру өчен чылатканнан соң орлыкларны чәчмичә озак тотарга һич тә ярамый.

Шулай ук колхозларның һәм совхозларның игтибарын түбәндәгеләргә юнәлдерергә кирәк: орлыкларны яровойлаштыру срогы төгәлләнмәү аларны чәчүне тоткарлау өчен сәбәп була алмый.

Бөртекле сабан ашлыгын яровойлаштыру өчен һава аеруча күп керә торган бинадан файдаланырга кирәк, моның өчен орлыкларны яңгырдан саклый торган лапаслар яхшырак була.

Тишелеп чыгуы түбән булган орлыклар яровойлаштыру өчен яраклы булмыйлар. Тишелми торган орлыкларның яровойлаштырган вакытта күгәрүләре һәм таза орлыкларны да бозулары мөмкин.

Яровойлаштыру өчен алынган орлыкны чылатканда инструкциядә күрсәтелгәннән артык су коймауны да нык күзәтергә кирәк. Йомшак сорт бодайның һәм иртә өлгерә торган каты бодайның һәр центнеры өчен 31 килограмм, соң өлгерә торган каты бодайның һәр центнеры өчен 33 килограмм, сабан арпасының һәм солының һәр центнеры өчен 35 килограмм су кирәк.

Яровойлаштырган вакытта яровойлаштырыла торган каты һәм йомшак бодай орлыкларында яровойлаштыру ахрына җиңелчә үргән орлыкларның 5 проценттан күп булмавын күзәтергә кирәк. Арпа һәм солы орлыкларында үргән орлыклар бөтенләй булмаска тиеш; бу орлыкларда үренделәр кабык эченнән чыкмаска тиешләр.

Шулай ук бодай орлыкларының каты гөмбәдән „АБ" препараты белән чистартуны да күздә тотарга кирәк. Аларны бакыр купоросы белән, шулай ук Давыдовның мышаяк препараты белән һәм Париж зелены белән агуламаска кирәк; болар белән агулаганда яровойлаштыру вактында орлыкларның тишелеп чыгулары шактый кимергә мөмкин.

Колхозларда һәм совхозларда яровойлаштыру буенча әлбәттә инструктив күрсәтмәләр—бөртекле сабан ашлыгын яровойлаштыру турында СССР Наркомземы чыгарган плакат, яки авыл хуҗалыгы үсемлекләрен яровойлаштыру буенча 1936—37 нче елларда Сельхозгиз чыгарган китап булырга тиеш. Бу күрсәтмәләрне җентекләп өйрәнергә, узган еллардагы тәҗрибәгә анализ ясарга һәм 1940 нчы елны орлыкларны яровойлаштыру эшен шулар нигезендә үткәрергә кирәк.

(„С. З." дән кыскартып алынды)

Чит илләрдә

Иптәш В. М. Молотовның СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясендә ясаган докладына турында чит ил матбугаты

ФРАНЦИЯ

ПАРИЖ, 1 апрель. (ТАСС). Парижда чыга торган барлык газеталар, иптәш Молотов докладына турында отчетлар бирел, аларга кин күләмдә аңлатмалар язалар. Аеруча зур газеталар, аерым алганда „Пти паризьен", „Журналь", „Эпок", „Эвр" һәм башка газеталар доклад турында тулы отчетлар урнаштыралар. „Ордр", „Виктуар", „Жюстис" һәм „Эвр" газеталары мәкаләләренең башларында „Франция СССР нең политикасы нейтралитет" дип күрсәтәләр. Күп кенә газеталар—„Тан", „Пари суар", „Пти паризьен" һәм башка газеталар—иптәш Молотов докладының интересләгән һәм сугыш утын кабызучыларның үләрын һәм аларның Финляндиядәге планнарының җимерелуен фаш итү турындагы урыннарын ачыктан-ачык ачу белән күрсәтеп үтәләр. Бу газеталар үзләренең аңлатуларын Советка каршы тупас чыгышлар белән бергә алып баралар. Аерым алганда, Франция матбугатының Советка каршы [illegible] „Эпок" һәм „Ордр" газеталары, хәзерге сугышта СССР ның политикасы—„чын нейтралитет политикасы" дип таныйлар. „Ордр" газетасы, „СССР барлык илләргә, шулай ук Финляндиягә карата да үзенең тынычлык политикасын саклады" дип күрсәтә.

РУМЫНИЯ

БУХАРЕСТ, 2 апрель. (ТАСС). Румыниянең бөтен матбугаты Совет хөкүмәтенең тышкы политикасы турында иптәш Молотов докладын аңлатуны дәвам иттерә. Газеталар барсы да „Правда" газетасының 31 нче марттагы баш мәкаләсе турында Румыния телеграф агентлыгы „Радор" ның белдерүен урнаштыралар. Газеталар нейтралитет политикасы үткәрүче һәм көнбатыш державаларның империалистик интересларының коралы булып әверелергә теләмәүче Советлар Союзының тышкы политикасын бәйсезлеге турында иптәш Молотов белдерүенә аерым күрсәтеп үтәләр.

„Универсул" газетасы, иптәш Молотов докладын—хәлыкара тынычлык өчен әһәмиятле вакыйга дип бәяли. Газета төньяк илләренең оборона союзы дигән нәрсәләргә карата Советлар Союзының нык позициясен күрсәтеп үтә.

ӘФГАНСТАН

КАБУЛ, 2 апрель. (ТАСС). „Ислах" газетасы СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе ачылуы турындагы белдерүне һәм Советлар Союзының тышкы политикасы турында иптәш Молотов докладының эчтәлеген басып чыгарды. Газета Сессия депутатлары Советлар Союзының тыныч тышкы политикасын бердәм рәвештә яхшы дип таптылар дип күрсәтеп үтә.

АНГЛИЯ

ЛОНДОН, 1 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең барлык газеталары иптәш Молотов докладының тулы эчтәлеген игълан иткәннәр.

Англиядә чыга торган газеталарның күпчелеге докладта СССР ның союзниклар белән, шулай ук СССР ның көньяк-көнчыгыш Европа илләре белән мөнәсәбәтләре турында әйтелгән өлешен аеруча тулы итеп игълан итәләр.

Англиянең реакцион матбугаты, аерым алганда „Дейли телеграф энд Морнинг пост" газетасы докладның СССР белән Англия арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы өлешен аерым күрсәтә. [illegible]

„Санди таймс" газетасы һәм күп кенә башка газеталар, укучыларны СССР позициясенең [illegible]

Хәтта „Дейли геральд" газетасы да иптәш Молотов докладына белән бирә: „Молотов: Без—сугыштан читтә торабыз. Советлар тәләкләре бикале: без Англия—Франция политикасының коралы булмаячакбыз".

„Дейли экспресс" һәм „Санди таймс" газеталары, шулай ук „Рейнольдс ньюс" газетасы „Англия хөкүмәте белән СССР арасында сөйләшүләрне яңартырга" дип чыгалар.

ГРЕЦИЯ

АФИНА, 2 апрель. (ТАСС). Грециянең барлык газеталары иптәш Молотов докладының тулы эчтәлеген урнаштырганнар. Күпчелек газеталар доклад турында [illegible] СССР ның тышкы политикасын тынычлык [illegible] һәм аның нейтралитет позициясен [illegible] күрсәтеп үтәләр.

ИРАН

ТАҺРАН, 2 апрель. (ТАСС). Кичә Таһрандагы барлык газеталар иптәш Молотов докладының берничә [illegible] урнаштырдылар.

Болардан тыш иптәш Молотов докладының Советлар Союзының Иранга һәм Төркиягә карата политикасы турындагы өлешен аерым чыгардылар.

ЯПОНИЯ

ТОКИО, 2 апрель. (ТАСС). Домей Цусин агентлыгы, иптәш Молотов докладына япон газеталарының откликларын тапшырып, „Кокумин" газетасы Советлар Союзының позициясенә яхшы бәя бирә дип күрсәтә. Газета болай дип яза: „Япон—Совет мөнәсәбәтләрен яхшырту өчен Токионың үз позициясен ачыграк итүе кирәк".

ПОЛЬША ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЭЛЕККЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕН ХӘРБИ СУДКА БИРҮ ТУРЫНДА ГЕРМАНИЯ АГЕНТЛЫГЫНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

БЕРЛИН, 2 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, элекке Польша парламентының Анжерда качып ятучы членнары элекке чит ил эшләре министре полковник Бекны, Польша армиясенең элекке баш командующие Рыдз-Смыглыны һәм элекке баш министр-генерал Славой - Складовскийны хиянәт итүләре өчен хәрби судка бирүне таләп итеп карар чыгарганнар. Рыдз-Смыглы „илне саклау буенча җитәрлек чаралар күрмәүдә, сугыш алып барырга сәләтсез булуда һәм, ниһаят, Польша гаскәрләре көрәшне дәвам иттергәндә чит илгә качуда" гаепләнә.

Франция цензурасы бу карарга кагылышлы булган бер генә хәбәрне дә үткәрми һәм шулай ук Англия хәбәрчеләренә моның турында үзләренең Лондондагы газеталарына хәбәрләр җибәрүләренә комачаулык итә.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 2 апрель. (ТАСС). Кичә кичке белдерүдә болай диелә: „Саардан көнбатыштарак районда артиллериядән аеруча еш ату булды.

Ике якның да артиллериясе нык активлык күрсәтте. Һавада күп кенә сугышлар булды. Аларның нәтиҗәләре әле маглүм түгел. Франциянең барлык самолетлары үз базаларына кайттылар.

31 нче мартта Франция истребительләре звеносы дошманның шактый күп көчләрен очратты. Франциянең ике самолеты бәреп төшерелде. Калган самолетлар үз базаларына кайттылар".

Бүгенге иртәнге белдерүдә: „Бөтен фронтта төн тыныч үтте" диелә.

БЕРЛИН, 2 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе игълан иткән сводкада болай диелә:

„Көнбатыш фронтта бер нинди әһәмиятле" вакыйгалар булмады. Кичә Германия авиациясе Төньяк диңгез һәм Көнчыгыш Франция өстендә көчле разведка ясавын дәвам иттерде. Шул вакытта Германиянең аерым разведка самолетлары белән дошман истребительләре арасында күп тапкыр сугышлар булды. Германиянең 2 разведка самолеты французларның ике истребителен бәреп төшерде. Германия бухтасына үтеп керергә маташканда Англиянең бер разведка самолеты бәреп төшерелде. Германиянең бер самолеты очыштан кайтмады".

Кытайның милли-политик советының сессиясе

ЧУНЦИН, 1 апрель. (ТАСС). Бүген иртә белән Чунцинда Кытайның милли-политик советының V нче сессиясе ачылды. Сессиядә японнар алган районнардан күп кенә вәкилләр катнашалар. Делегатлар арасында Монголиядән, Синьцзяннән, чит илләрдәге Кытай эмигрантларыннан һәм башкалардан вәкилләр бар. Фронтларда сугыш операцияләренә җитәкчелек итүче күп кенә делегатлар сессиягә килә алмадылар.

Совет председателе Чан Кай-шиның һәм аның урынбасары—профессор Чжан Болинның кереш речендән соң сессиянең тантаналы өлеше ябыла.

Сессиянең көн тәртибендә түбәндәге мәсьәләләр тора: 1. Югары хәрби совет секретаре Чжан Цюньның политик докладлы, 2. Фронтлардагы хәл—Кытайның сугыш министре Хо-Ин-цин докладлы, 3. Финанс политикасы, 4. Мәгариф мәсьәләләре, 5. Экономика мәсьәләләре. Сессиянең соңгы көне совет членнарының сорауларына һәм такдимнәренә багышланачак.

ЧАН КАЙ-ШИ РЕЧЕ

ЧУНЦИН, 2 апрель. (ТАСС). Кичә, милли-политик советның бишенче сессиясен ачканда Чан Кай-ши речь сөйләде. Фронтлардагы хәлләргә кагылып, Чан Кай-ши, японнар Хунань провинциясенең төньяк өлешендә, Гуандун һәм Гуанси провинцияләрендә, шулай ук Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә һөҗүм итәргә маташып, уңышсызлыкка очрадылар, дип белдерде.

Япониянең хәлен характерлап Чан Кай-ши болай диде: „Япония политика һәм экономика ягыннан котылгысыз һәлакәткә якынлашып килә. Азиядә тынычлыкны җимереп, Япония Ерак Көнчыгышта өченче дәүләтләрнең законлы хокукларын юк итү теләге белән „яңа тәртип" төзергә маташа. Көчле, икеләнүләрдән соң зур кыенлыкларны кичереп, Япония, Нанкинда курчак хөкүмәте төзү өчен ярдәмгә Ван Цзин-вейны, Ван Кә-минны һәм Лян Хуи-чины чакырырга карар биргән. Ван Цзин-вей һәм башка хыянәтчеләр юк ителергә тиешләр. Без көчләребезне һәм каршылык күрсәтүне дәвам иттерергә, омтылышыбызны икеләтә арттырырга тиешбез. Тәмам җиңүгә ирешү өчен без нык фундамент салдык".

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

Көньяк Кытайда. Наньнинан көньяк-көнбатыштарак, Фунань районында сугышлар дәвам итә. Бу секторда кытай гаскәрләре японнарны бер пункттан бәреп чыгардылар.

Кантоннан көнбатыштарак, Самшуй районында японнар һөҗүм ясаганнар иде, ләкин кире кагылдылар.

Төньяк Кытайда. Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә, Уюань тирәләрендә кытай гаскәрләре японнарның бер отрядын тар-мар иттеләр. Японнар 200 ләп кешеләрен югалттылар. Кытайлар сугыш кирәк-яраклары, шул исәптән артиллерия снарядлары һәм винтовка патроннары кулга төшерделәр.

Үзәк Кытайда. 30 нчы мартта Чжэцзян провинциясендә, Сяошань тирәләрендә сугышлар булды. Кытай гаскәрләре шәһәр янындагы бер авылдан японнарны бәреп чыгардылар.

2 апрель. (ТАСС).

Хэллның белдерүе турында Америка матбугаты

НЬЮ-ЙОРК, 1 апрель. (ТАСС). АКШ ның дәүләт секретаре Хэлл Ван Цзин-вейның курчак хөкүмәтен гаепләп белдерү ясаган иде. Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, чит ил эшләре буенча сенат комиссиясе председателе Петтмэн түбәндәгеләрне белдергән: „Мин дәүләт секретаре Хэллның белдерүен чын күңелдән яхшы дип табам. Нанкиндагы хәзерге хөкүмәт Кытай хөкүмәте түгел, бәлки ул Манчжоу-Го кебек үк курчак хөкүмәт". „Нью-Йорк таймс" газетасы, Ван Цзин-вейның „курчак хөкүмәте төзелү" Кытайда интереслары булган АКШ һәм барлык илләр өчен чиктән тыш җидди вакыйга" дип яза. Аннары газета болай ди: „Ачык ишекләр" политикасын урнаштырырга вәгдә бирүенә карамастан, Ван Цзин-вей хөкүмәте Япония теләкләре өчен төзелгән һәм япон штыклары һәм япон пропагандасы ярдәме белән яши. Һич шиксез, бу хөкүмәт яшрен килешүгә таяна, бу килешү буенча Япония Кытайның Ван Цзин-вей кулындагы өлешен Япониянең вассалына әйләндерү өчен монополия хокукы ала".

Англиянең Токиодагы илчесе Крейгиның „гаҗәп белдерүе"ннән ачыктан-ачык борчылып, газета, АКШ ның һәм 9 держава договорына кул куйган башка илләрнең, Ван Цзин-вей территориясен танымаулары турында тиз арада белдерү ясауларын таләп итә. Аннары газета болай ди: Чан Кай-ши хәзерге вакытта элеккегегә караганда да зуррак ярдәм белән файдалана.

„Нью-Йорк таймс" газетасының Вашингтондагы хәбәрчесе, Хэллның белдерүе АКШ ның Ван Цзин-вейны танырга теләмәвен ачык күрсәтә, дип яза.

Казан аэроклубы отличник курсантлары. Сулдан—Павел Евдокимов һәм Иван Иванушкин иптәшләр занятие вактында.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

„Коммуна" газетасының 10 еллыгы

ВКП(б) ның Азнакай райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы „Коммуна" газетасының чыга башлавына 10 ел тулу уңае белән 25 нче мартта юбилей үткәрелде.

„Коммуна" газетасы авыл хуҗалыгын яңа баштан үзгәртеп коруру, массовый күләмдә колхозлар оештырыла башлау чорында чыга башлаган иде. Газета колхозларны оешу-хуҗалык ягыннан ныгытуда шактый зур роль уйнады. Шушы 10 ел эчендә бу газета 905 номер чыкты һәм үзенең битләрендә 16.318 материал, шул исәптән хәбәрчеләрнең 8.500 дән артык хатларын урнаштырды.

Юбилей уңае белән хәбәрчеләр һәм стена газеталары редакторлары катнашында җыелыш үткәрелде.

Д. Зиннуров.

КОЛХОЗЛАРДА ЭЛЕКТР СТАНЦИЯЛӘРЕ

Быел Татарстан колхозларында 7 урында электр станцияләре төзү тәгәлләнә. Аларны салып бетерү һәм җиһазлау өчен Авыл Хуҗалыгы банкысыннан 100 мең сум кредит билгеләнде.

Мамадыш районының „Рассвет" һәм „Красный починок" колхозлары өчен Омарка елгасында 45 киловаттлы, Теләче районының „Чулпан № 2" һәм „Марс № 2" колхозлары өчен Мишә елгасында 45 киловаттлы гидростанцияләр салына. Чепья районының Буденный исемендәге колхозында 100 киловаттлы электр станциясе төзелә. Бу станциянең энергиясеннән берничә колхоз файдаланачак.

Аксубай районының „Большевик", „Прожектор", „Украинец", Алабуга районының „Красный Партизан", Кайбыч районының Фрунзе исемендәге колхозлары өчен төзелә торган электр станцияләре дә быел эксплоатациягә биреләләр. Колхозлар электр энергиясен тегермәннәрне хәрәкәтләндерү, ашлык сугу, шулай ук колхозчыларның өйләрен яктырту өчен файдаланачаклар.

ТОРФ ЧЫГАРУ

Куйбышев гидроузелы төзелеше уңае белән Волга һәм Кама буйларында су басарлык булган сазлыклардагы торфларны чыгарып бетерү чаралары күрелә. Столбище, Лаеш, Алексеевский, Куйбышев, Югары Ослан районнарында һәм башкаларда 2 мең гектардан артык мәйданда өстәмә рәвештә торф чыгару оештырыла. Бу эшләргә 715 мең сум акча билгеләнде. Бу торф мәктәпләрне, больницаларны һәм җәмагат биналарын җылыту, шулай ук кирпеч яндыру өчен файдаланылачак.

ЕЛГАЛАРДА

Елгаларда су арту дәвам итә. 3 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Волга суы Горький янында 10 сантиметр, Вязовые янында 24 сантиметр, Югары Ослан янында 28 сантиметр, Кама Тамагы янында 56 сантиметр, Тәтеш янында 31 сантиметр артты. Ташу башланганнан бирле Югары Ослан янында арткан су 186 сантиметрга җитте. Астрахань янында боз ага. Вязовые һәм Кама Тамагы янында Волга аркылы атлыларның чыгып йөрүләре туктатылды.

Кама суы соңгы бер тәүлек эчендә Молотов шәһәре янында 2 сантиметр, Красный Бор янында 29 сантиметр, Чистай янында 26 сантиметр, Лаеш янында 30 сантиметр артты. Красный Бор янында Кама бозы өскә күтәрелде.

Ока елгасында Белев янында боз ага. Калуга янында боз тыгылып тора. Муром янында Ока суы 23 сантиметр артты. Иж суы Әгерҗе янында 30 сантиметр, Мишә суы Рождествено янында 12 сантиметр, Казанка суы Казан янында 29 сантиметр артты.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛАР

Магазиннан урлау. Милиционер иптәш Нестягин Тукай урамында төенчекләр күтәреп баручы ике кешене күреп туктарга кушкан. Билгесез кешеләр аның тавышын ишеткәч тә, төенчекләрне ташлап качканнар. Төенчекләрдән 16.845 сумлык промтоварлар табылган. Бу әйберләр йозак вату юлы белән Горпромторгның 3 нче магазиныннан урланган булган. Әйберләрне магазинга кайтарып биргәннәр.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
5 нче апрельдә, шулай ук 6 нчы апрельдә көндез һәм кич
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 4 нче апрельдә
В. Шкваркин әсәре премьера
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Иртәгә, 5 нче апрельдә
МАСКАРАД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген, 4 нче апрельдә
ИРЕК
7 нче апрельдә Зур театр бинасында
ФАУСТ
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгаттә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм ҖИР ПЛЕНДӘ
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК

Казан Дәүләт Мединституты Акушерка-Гинекология клиникасының оваль формадагы урланган печатен гамәлдән чыккан дип саңарга. 574—1

ШАГЫЙРЬ ӨЕНДӘ

(В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга карата)

Маяковский белән очрашуларымны уйлый-уйлый, башымны түбән иеп, бөек шагыйрь яшәгән йортка керәм.

Бу йорт хәзер Маяковский китепханәсе-музее дип атала. Шундагы бүлмәләрнең берсендә шагыйрьнең әнисе—Александра Алексеевна, беренче тапкыр әдәби кичәдә чыгар өчен улына яңа күлмәк тегә. Шул йортта Володя Маяковский җанҗаллы әдәби чыгышлардан соң туганнары янында ял итә. Шул йортта Владимир Маяковский үзенең байтак әсәрләрен яза һәм шунда ул үзенең егерме еллык әдәби бәйрәмен уздыра.

Баскыч буйлап без югарыга, икенче катка күтәреләбез. Стеналарга карыйбыз. Анда революция җырчысының лозунг урнында йөргән үткен шигырьләре эленгән.

Беренче бүлмәгә керү белән үк, күзләр зур ихтирам белән әйтелгән һәм пыялага язылып куелган җылы сүзләргә төшәләр:

„Маяковский—безнең совет чорыбызның иң яхшы, иң талантлы шагыйре иде һәм ул шулай булып калыр да".
(СТАЛИН).

Әле яңа гына ачылган бу әһәмиятле музейнең беренче экскурсантларын шагыйрьнең туганы—Людмила Владимировна каршы ала. Без залга узабыз. Людмила Владимировна безне Маяковскийның бала чагы белән таныштыра, шагыйрь турында үзенең истәлекләрен сөйли.

— Безнең семьябез,—ди ул,—Володяның бала чагында ук революционерлар белән якын бәйләнештә тора иде. Әти 1906 нчы елны үлде. Аны күмгәннән соң безнең барлык 3 сум гына акчабыз калган иде. Без ярлы яшәдек. Шуңа күрә бүлмәләргә квартирантлар җибәрергә туры килә иде. Безгә революцион яшьләр урнаштылар һәм алар Володяның иң якын дуслары булып киттеләр. Володяның революцион хәрәкәткә яштән катнашып китүе дә, патшага каршы әче сүзләр язуы да, төрмәгә эләгүе дә әнә шулай башлана.

Людмила Владимировна безгә яш Маяковскийның төрмәдән язылган хатларын күрсәтә һәм аларга аңлатмалар бирә.

— Без семьядә бөтенебез дә рәсем ясый идек,—дип ул, тагын сөйли башлый. Аның сүзләреннән без Маяковскийның яхшы художник булуын һәм Москвада рәсем мәктәбенә укырга керүен аңлыйбыз.

Людмила Владимировна белән сөйләшкәннән соң без музейне карарга керешәбез. Пөхтә итеп хәзерләнгән материаллар монда төрле темалар нигезендә аерым-аерым бүлекләргә тупланганнар.

Беренче бүлек—шагыйрьнең бала чагы. Бу бүлеккә карап без Маяковскийның гүзәл Грузиядә урманчы семьясендә тууын беләбез. Әтисе аңа яхшы тәрбия бирергә тырышкан. Маяковский бала вакытта ук гаять зиһенле, тапкыр сүзле, зирәк һәм житез булып танылган. Рус телен яхшы үзләштерү белән бергә, грузинчә дә сөйләшергә өйрәнгән.

Икенче бүлек—Маяковскийның большевиклар партиясенә керүен, аның пропагандист булып эшләвен күрсәтә.

Өченче бүлек—„Яңа сәнгат өчен көрәштә" дип атала. Монда без шагыйрьнең шул чорда (1910—12 нче еллар) язылган бунтарь шигырьләреннән өзекләр укыйбыз.

Маяковскийны беренче тапкыр талантлы шагыйрь итеп таныткан „Штанлы болытлар" поэмасы аерым бүлек итеп күрсәтелә. Революцион хәрәкәткә катнашып, үзенең аның кинәйткән шагыйрь 1914 нче елда ук революциянең якынлашуын хәбәр итә.

Империалистик сугышның йөзенә Маяковский әче рифмалар белән төкерә.

Маяковский шигырьгә форма һәм эчтәлек яңалыгы алып килде. Әдәбиятны тормыштан ераклаштырган язучыларга каршы ул баш күтәрде. Мешчәнлеккә каршы бунт ясады. Буржуа матбугаты Маяковскийны штыкларга алды, аның шигырьләреннән көлде. Яш талант фамилиясе белән янәшә хурлау сүзләре языла башлады. Маяковский катнашы белән ясалган кичәләрдә дистәләрчә полицейскийлар һәм жандармнар скандал көтеп утырдылар.

Менә шушындый тынчу һавада Маяковскийны яклап чыккан бердән-бер батыр тавыш—бөек Максим Горький тавышы иде. Буржуа тәнкыйтчеләренә каршы чыгып, Горький болай ди:

— „Мисальгә сез Маяковскийны алып карагыз: ул яш, аңа бары 20 генә, ул акыручан, ләкин, һич шиксез, талантлы ул. Аңа эшләргә, укырга, өйрәнергә кирәк һәм ул менә дигән яхшы шигырьләр язачак. Мин аның шигырьләр китабын укып чыктым. Бу китап чын сүзләр белән язылган".

„Маяковский һәм Горький" дигән бүлектә менә шуның кебек тарихи әһәмияте зур булган бик мөһим материаллар тупланган.

„Бөек Октябрь елларында" дигән бүлек иң бай бүлекләрдән санала. Монда без Маяковскийның социалистик революцияне котлап язган „150.000.000" шикелле зур поэмаларын, „Сул марш" шикелле маршларын, Кызыл Армиянең батырлыгын җырлаган шигырьләрен, Колчак һәм Деникиннәрдән көлгән сатираларын күрәбез.

Ул данлы елларда Маяковский РосТА да эшли. Фронттан алынган хәбәрләр буенча рәсемнәр ясый һәм рәсемнәргә шигырь белән аңлатмалар яза. Шатлыклы хәбәрләрне халыкка тизрәк җиткерү өчен төннәр буенча иҗад итә. Ял итәргә ятканда да озак йокламас өчен баш астына утын агачы куеп ята.

Маяковскийның шул чордагы тау кадәр эшләренә карап, аның революцион эшкә, Советлар власте өчен көрәшкә ни кадәр тирән, ярсу бирелгәнен күрәсең!

Революция җырчысының һәрбер көне иҗадта үтә. Аның шигырь язмыйча уздырган көнен күрсәтү кыен. Менә 1921—1924 нче еллар. Алар төрле-төрле поэмалар, пьесалар һәм шигырьләр белән тулган.

Бөек Ленин образын матур әдәбиятта беренче тапкыр Маяковский күтәреп чыга һәм поэзиядә хәзергә тиңдәше булмаган „Ленин" поэмасын бирә. Без бик озак Ленин рәсменә карап торабыз. Шул рәсемгә карап, Маяковский Ленин турында иң җылы, иң кайнар шигыри сүзләрне язган.

Маяковский—халык шагыйре. Ул замамыбызның иң күп йөргән кешесе. Күпләр аны укып кына түгел, күреп тә беләләр. Маяковский үзенең укучылары белән күзгә күз сөйләшә. Ул 56 шәһәрдә була. Ике тапкыр Казанга килеп китә. Һәр җирдә ул әдәбият турында докладлар ясый, шигырьләр укый. Маяковский кичәләре совет әдәбиятын халыкка якынайтуда гына түгел, политик яктан да зур роль уйныйлар. Советлар иленең „Шигырь полпреды" булып Маяковский 9 тапкыр чит илдә була. Чит илгә ул Советлар Союзы турында намуслы шагыйрьнең турылыклы сүзен илтә, буржуа матбугатындагы уйдырмаларны юкка чыгарып, безнең чынбарлыгыбызны җырлый. Аның чит илләрдәге чыгышлары революцион шагыйрьләр иҗадына нык тәэсир итә.

Маяковский газетага иң якын торган политик лирик. Без аның хәбәрчелек билетларын карыйбыз. Алар санап бетергесез. Менә газеталар: „Известия", „Комсомольская Правда"... Шунсы кызык: Маяковский газетага шигырьләр белән генә катнашмый, ул укучының игтибарын җәлеп итәрлек исемнәр, „шапка"лар таба, сәхифәләр оештыра. Газетада катнашуга ул гаять мактаулы һәм җаваплы эш дип карый. Анда ул югары сыйфатлы әсәрләр бирә.

Без, телефон эленеп торган зур бүлмәгә узабыз. Өстәл. Өстәлдә газета. Бала чагында ук Маяковский әллә ничә километрга газета алырга бара булган. Газетага булган мәхәббәте аның гомеренең соңгы көненә хәтле сакланган. Редакцияләрдән телефон шалтыраганда инде политик вакыйгаларга карата аның үткен шигырьләре күптән язылып беткән булалар. Ул тормышның эчендә кайный һәм шул тормышны үз иҗадында тулы итеп чагылдыра.

Бу бүлмәне без озак карыйбыз. Монда зур-зур кичәләр ясалган, Асеевларның, Кирсановларның һәм бүтән шагыйрьләрнең поэмалары укылган. Шунда ук Маяковскийның егерме еллык юбилее уздырылган. Шунда шагыйрь башкала большевиклары алдында шигырьләр белән чыгуга хәзерләнгән. Заманыбызның иң талантлы шагыйрен тыңлар өчен башкала большевиклары активы махсус чакыру ясый. Тирән дулкынлану, гади бер тыйнаклылык белән Маяковский үз иҗады турында хисап ясый, шигырьләр укый. Аны тыңлап, Куйбышев шикелле большевиклар матур әдәбият биргән рәхәт сәгатьләрне кичерәләр.

Без шагыйрьнең кабинетына узабыз. Пальтосын, эшләпәсен, таягын карыйбыз. Өстәл. Өстәлдә китаплар, сәгат, ручка. Читтәрәк юл мендәре һәм чемодан. Бу әйберләргә карап төрле уйларга чумасың. Гуя Маяковский үлмәгән, ул яңа гына сәяхәттән кайткан һәм гадәте буенча юынырга гына чыккан... Менә ул хәзер кайтып керер дә:

— Йсәнмесез, дуслар!—дип күрешер төсле тоела.

Г. Кутуй.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1350 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1247.